Мөхәммәт
Мирза

# Биш юлым-
# биш гөлем

Шигырьләр

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2013

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5
М51

**Мирза, М.**

Биш юлым – биш гөлем : шигырьләр / Мөхәммәт Мирза ; [кереш сүз авт. Р. Ганиева]. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2013. – 207 б.

ISBN 978-5-298-02391-7

Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Мөхәммәт Мирзаның бу китабына тупланган бишьюллыклар сәнгатьчә фикерләүнең яңалыгы белән укучының игътибарын җәлеп итә. Гомумкешелек кыйммәтләрен алга сөргән, тирән фикерле, универсаль эчтәлекле әлеге шигъри бәйләм – авторның зур уңышы.

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5

ISBN 978-5-298-02391-7

© Татарстан китап нәшрияты, 2013
© Мирза М., 2013

## Акыллы сүз белән рухи-әхлакый яңарышка таба

Гасырлар алмашу Россия дигән уртак Ватаны-бызның сәяси-икътисади, мәдәни-әдәби барышында кискен үзгәрешләр китереп чыгарды. Ничәмә-ничә гасырлар дәүләтчелеген югалту ачысын йота-йота толерантлык күрсәтеп яшәгән татар халкының да үзаңы уянып китте. Узган тарихта ике мәртәбә – Болгар, Алтын Урда, Казан ханлыгы дәверләрендә һәм XX гасыр башында – иҗтимагый-мәдәни күтәрелеш кичергән милләтебез, кабат талпынып, тернәкләнү, алгарыш өчен көрәш-тартышлар мәйданына аяк басты.

Милләтпәрвәрләребезнең тырышлыгы белән бу уяну, кузгалышның нигез ташлары салынды, совет чорында югалта язган, кыерсытылган телебезне, динебезне, гореф-гадәтләребезне, тарихи хәтеребезне, Гаяз Исхакый мирасын халкыбызга кайтару бәхетенә ирешелде. Беренче Президентыбызның фатихасы белән үзебезнең дәүләтле, мәдәниятле халык икәнлегебезне искә төшереп, азатлыкка, мөстәкыйльлеккә омтылышыбызны символлаштырып, Кол Шәриф хәзрәтләре хөрмәтенә мәһабәт мәчет бастырып кую үзенә күрә бер рухи җиңү иде. Әмма XX гасырның азагында үзгәртеп кору җилләре белән башланып киткән бу яңарыш хәрәкәтенең гомере, умырзая чәчәгенеке кебек, бик тә кыска булды. Ул яшәешебезнең һәр өлкәсендә, аеруча милли дәүләтчелек атрибутларын саклауга омтылышыбызны, мәгарифне ээзрлекләгән түнтәрелеш белән алмашынды, «Мәскәү кулында алтатар – татарга!» (М. Мирза) дигән шик-шөбһәле шигарь хакимлек итә башлады. Тарих кабатланып килә, еш кына андагы вакыйгалар, мәдәни-әдәби күренешләр кире әйләнеп кайта, диләр. Түнтәрелеш дигән кара заман да үтәр дигән өмет белән яшәп, Тукайча: «Кисмәк өстендә каракош иттифакый (очраклы. – *Р. Г.*) кунган ул», – диясе килә. Чөнки, илдәге вәзгыять никадәр генә җайсыз, каршылыклы булмасын, халкыбызның гасырлар дәвамында тупланган мәдәни-әдәби байлыгы зур, салынган нигез ташлары нык. Әдәби барышның һәр өлкәсендә җигелеп эшләүче талантлы каләм әһелләре дә җитәрлек. Канатлы җайдакларын иярләп, милли мәнфәгатьләрне күздә тотып, Гаяз Исхакыйча, көрәш-тартышларга чакыручы шагыйрь һәм шагыйрәләребез иҗаты аеруча игътибарга лаек. Әдәби иҗат милли алгарышның беренче шарты дип ихлас инанган күренекле шагыйрьләребезнең берсе – Мөхәммәт Мирза (Ибраһимов Илфак Мирза улы).

Шагыйрь, журналист, җәмәгать эшлеклесе, җөмһүриятебезнең Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Мөхәммәт Мирза 1953 елның 3 гыйнварында, Сталин тоталитаризмы тарих сәхнәсеннән төшкән елда, Актаныш районының Чалманарат авылында дөньяга килә. Совет режимының кешелексез юлдашы булган репрессияләр, сугышлар аларның да нәсел-нәсәбен, ата-бабаларын читләтеп үтми. Дин әһеле (мөәзин) булган бабасы бай (ике аты була) дип тамгаланып, җиде баласын ятим калдырып, атып үтерелә. Оста биюе белән дан тоткан әтисе дә, унҗиде яше тулуга, фронтка озатыла, Киев өчен барган сугышларда Днепрны кичкәндә, унсигез яше тулган көнне, ике аягын өздерә; туган туфракка кайтып егылгач та, 41 ел дәвамында тимер протез белән йөри; мәктәптә тарих укыта, шактый еллар мәктәп директоры, берка-дәр вакыт авыл Советы секретаре вазифасын да башкара. Бала арбасы тартып, колхоз эшенә йөргән, искиткеч булганлыгы, уңганлыгы белән авылда дан тоткан хатыны Мөсәвәрә белән алар унбер бала тәрбияләп үстерәләр, аларның барысына да югары белем бирәләр. Ата-аналарының бу фидакярлеге, оста рәссам ясаган картиналардагы кебек, Мөхәммәт Мирзаның шигырьләрендә дә чагылыш таба. Балачакта, әнисенең итәгенә ябышып, ни рәвешле кырдан кайтып килүләрен ул болай тасвирлый: «Күз алдында җуелмаслык сурәт: / Бер менеп, бер төшеп буразнасын, / Басу буйлап әни кайтып килә, / Иңдә – чалгы, кулда – кул арбасы». «Әнкәй» дигән «Бөек Йолдыз» образы шагыйрьнең гомер һәм иҗат юлын бүген дә яктыртып тора. Сынмас рухлы, көчле шәхес итеп сурәтләнгән, аякларын югалткан әтисе образы да җанны тетрәтә: «Протезларын салып куйган әти... / Тубыкланып атлап килде дә / Алмаш-тилмәш безне күккә чөйде: / «Бөркетләрем минем!» – диде дә». Бу шигырь юлларын укыгач та, ихтыярсыз Нәҗип Думавиның «Ватан каһарманы, яки Агач аяк» хикәясендәге Шакир солдат образы искә төшә. Беренче бөтендөнья сугышыннан каты яраланып, авылга кайткан, улларын-кызларын ач үлемнән саклый алмаган, актык урагын да закладка салган Шакир – агач аяклы бик тә кызганыч солдат. Икенче бөтендөнья сугышыннан тимер аяклар белән кайткан Мирзамөхәммәт исә соңгы көннәренә кадәр хатыны, балалары өчен абруйлы Ата, зур гаиләнең матди һәм рухи терәге булып кала. Әтисенең рухи биеклеге алдында баш игән шагыйрь Илфак Ибраһимов үзенең әдәби тәхәллүсен дә Шәрык мәдәни дөньясында кабул ителгән этикет (әдәб) кагыйдәсе буенча «Мөхәммәт Мирза» дип кабул итә. Әтисе тәэсирендә яшь Илфак әдәбиятка тартыла, Һади Такташ, Муса Җәлил, Фатих Кәрим шигырьләрен

күңеленә сеңдерә; каләм тибрәтә башлый; армиядә хезмәт иткәндә дә шигърият белән кызыксынуын дәвам итә. Мәдәният институтының театр сәнгате-режиссура бүлеген тәмамлагач (1975), Актанышта җирле радиотапшырулар редакциясе мөхәррире, комсомол оешмасының беренче секретаре, эчке эшләр бүлегендә урынбасар, мәдәният бүлеге мөдире булып эшли, «Агыйдел дулкыннары» исемле әдәби иҗат оешмасын да әйдәп бара. Җитәкчелек эшендә шактый тәҗрибә туплаган белгеч буларак, Мөхәммәт Мирза Казанга күчерелә, дүрт ел Мәдәният министрлыгында урынбасар, җиде ел дәвамында Татарстан Язучылар берлегенең рәисе вазифасын башкара. Бүгенге көндә ул – кабат торгызылган, әмма кыс-ка гына вакыт аралыгында тарихыбыз, мәдәни-әдәби хәрәкәтебез турында эчтәлекле материаллар белән укучыларның игътибарын җәлеп иткән «Чын мирас» журналының баш мөхәррире.

Мөхәммәт Мирза шигърияткә өлкәнәйгәч, зур тормыш тәҗрибәсе туплап килде. Шуңа күрә еш кына үзенең язмаларында ул: «Мин – көзге шигырь», «Шагыйрьгә соңардың димәгез», – дип, укучыны кисәтеп куя. Анынча, «Көз ул – дөньяны танып белү, күз утыру, кирәкмәгән әйберләрне читкә кую». Аның бу фикеренә каршы чыгып, Ркаил Зәйдулла: «Шигъриятта биологик яшьнең әһәмияте юк. Туксанда да тупсада ятарга, алтыда алтын тәхеткә менәргә мөмкин», – дип каршы да чыккан иде. Әйе, моның шулай икәнлегенә дөнья һәм татар әдәбияты тарихыннан күп мисаллар китерергә мөмкин. Мәсәлән, Тукай бик тә иртә, гомеренең язында ук кулына каләм ала, язларда ук китеп бара. Сибгат Хәким гомер кояшы язлардан җәйләргә күчкәндә, Нури Арсланов җәйләрдән көзләргә аяк басканда, шагыйрьлек таҗын кияләр. Фарсы-таҗик Ренессанс әдәбиятының бөек шагыйре Сәгъди «Бостан», «Гөлстан» кебек мәшһүр әсәрләрен гомеренең көзендә генә – ничәмә-ничә дистә еллар сәфәрләрдә үткәреп, Ватаны Ширазга кайтып егылгач кына тәмамлый. Аурупаның даһи шагыйре Гёте үзенең атаклы «Көнбатыш-Көнчыгыш диваны»н, бик тә яшь Марианна исемле артисткага гашыйк булып, 70 яшендә генә иҗат итә. Таланты белән Гётены әсир иткән Габдрахман Җами үзенә дөньякүләм танылу алып килгән, җиде поэманы берләштергән «Җидегән йолдыз»ын гомеренең «алтын көзендә» – 60–80 яшьләр арасында язган. Шагыйребез Мөхәммәт Мирзаның «алтын көзләре» әле алда; әлегә ул, шәрыкчә әйтсәк, «гомер муенсасы»ның уртасында гына.

Узган гасырның сиксәненче елларында Мөхәммәт Мирза шактый уңышлы каләм тибрәтә. Туксанынчы еллар – шагыйрьнең жанрлар, сәнгатьчә фикерләү, дөньяга карашлар өлкәсендә үз алым-ысулларын, үз кыйбласын эзләгән чор. Аның хыял-максаты – канатлы атта җилдереп, шигърият биеклекләренә күтәрелү: «Толпарымны табасы бар. / Күтәрелеп Парнасыма, / Ир-ат исемен аласым бар». СССР таркалган, иҗтимагый формацияләр, идеологияләр алмашкан һәм дә сүз иреген кук капуслары ачылып киткән бу чорда аның «Кәккүк тавышын санадым» (1994), «Турайгыр» (1998) кебек шигъри җыентыклары дөнья күрә. Империянең рус булмаган халыкларны изү, юк итү сәясәте төрле жанр, тема, мотивларны берләштергән «Турайгыр» китабында постмодернистларча ачыктан-ачык, үтә кискен бәяләмәләр белән кире кагыла. Автор үткән тарихта шәһри Казанны яндырган, «биш гасыр кызыл кар яудырган», татар халкына вәхшидән-вәхши яу оештырган Явыз Иванны да, яңа заманда Чечня халкын канга батырган, үз илендә гражданнар сугышы башлап җибәргән сәясәтне дә борынгы грекларга хас булган чәнечкеле, бик тә усал, ачулы сардоник һөҗү белән тәнкыйть итә. Татар тарихының, Идел-йортның авыр сәхифәләре миниатюр сюжетларга, рецептив эстетика канунна-рына корылган поэмаларда укучы аңына тәэсирле итеп җиткерелә; сталинизм дәверендәге рәхимсез сыйнфый көрәшнең ничек итеп якташларына, авылдашларына, туган-тумачаларына, хәтта хуҗаларыннан тартып алынган атларга – Турайгырларга фаҗигаләр алып килүе нарратив (хикәяләү) поэтика һәм тирән психологик кичерешләр ярдәмендә ачып бирелә. Сиксәненче еллар азагыннан милли яшәешебездә башланган уңай үзгәрешләр дә автор игътибарыннан читтә калмаган. Ул ихлас күңелдән мәдәни-әдәби кыйммәтләрнең – «Идегәй» дастанының, Муса Җәлил, Хәсән Туфан, Гаяз Исхакый кебек каһарман затларның исемнәре һәм иҗатлары халкыбызга әйләнеп кайтуга куана, остазы Рөстәм Мингалим, зыялы замандашлары, сәнгать әһелләре, якыннары турында язылган шигырьләрен милли сагыш һәм гамьнәр белән үрелгән якты лирик буяуларда сурәтли.

XXI гасырның беренче ун елы – Мөхәммәт Мирза иҗатының яңа шигъри жанрлар үзләштерү һәм фәлсәфилеккә таба юл алу чоры. Ул бер-бер артлы «Киек Каз Юлында» (2003), «Тере су» (2007), «Адәм баласы» (2009), «Агыйделдә ак пароход» (2009), «Гыйбарәләр» (2010), «За той рекой» – «Елганың аргы ягында» (2011, рус һәм татар телләрендә) исемле китапларын бастырып чыгарды. Шигырьләренең байтагы башкорт, төрек, рус, инглиз телләренә тәрҗемә ителде.

Мөхәммәт Мирза шигъриятенең көтелмәгәнчә өр-яңа сыйфатлар белән баюында заманаларның үзгәрүе, дәһри совет режимының сәхнәдән төшеп, тыелган ислам мәдәнияте кыйммәтләренең, Коръән тәгълиматының реабилитацияләнүе зур әһәмияткә ия булды. Аксиома рәвешен алган бер

кагыйдә бар: кайда гына булмасын, Шәрык һәм Гареб халыкларының дөньяви алгарышы кайчандыр ниндидер сәбәпләр белән юкка чыккан традицияләрне кире кайтарудан һәм дини Яңарыштан башлана. Моның шулай икәнлегенә төшенгән шагыйрь әле гасырлар чигендә «Мәңгелек сорау» исемле дүртьюллыгында болай дип язган иде: «Гел яңаны эз-ләп табабызмы, / Табып югалтканны күптәннән? / Киләчәккә таба барабызмы, / Кайтып киләбезме үт-кәннән?»

Тирән эчтәлекле, универсаль яңгырашлы, вакыт агышын өч яссылыкта (үткән, бүген, киләчәк) постмодернистларча үреп биргән бу шигъри юллар Мөхәммәт Мирза иҗатының асыл мәгънәсен аңлауга ярдәм итүче ачкыч вазифасын үти. Юкка гына ул аны «Тере су» китабының тышлыгында үзенең төп иҗат шигаре рәвешендә кабат урнаштырмаган. Дөрестән дә, халкыбыз кайчандыр бабаларыбыз ерак тарихтан, мөселман мәдәнияте җирлегеннән тапкан, «яңа» дип «кабул иткән», аннары «югалткан» кыйблабызга кайтып килә; Коръән-Кәрим белән иңгән рухи кыйммәтләрне һәм ислам әдәбиятларының (гарәп, фарсы, төрки) һәр өч юнәлеше – дини-әхлакый, суфичылык, дөньяви Яңарыш әдәбиятларына хас казанышларны яңабаштан иҗади үзләштерергә омтыла.

«Тере су» шигъри җыентыгының исеме символик яңгырашлы. Геологларның гыйльми язмаларына таянып, автор, гасырлар дәвамында мәңгелек бозлавыкны ашап, тишеп, боз катламнары карынында күлләр ясап, вулканнардай ярсып, диңгез-океаннарга ыргылучы тере су образында тарихи барышта мәңгелек хәрәкәттә булган, авырлыкларны җиңеп алга баручы Кеше образын символлаштыра, аның җирдәге миссиясенә мәдхия укый. Сүз уңаенда шуны да искәртеп үтәргә кирәк: Шәрык классик әдәбиятында, мәсәлән, Низами Ганҗәви иҗатында, аның икенче мәгънәсе дә очрый: тере су – иҗат кешесе каләменнән тамган, хәрефләр дулкыны сыман агып барган уй-фикерләр һәм хис-кичерешләр.

Жанрлар төзелеше ягыннан китап үзенчәлекле: анда берьюллыклардан башлап сигезьюллык шигырьләргә кадәр бирелгән. Кош теледәй кыска мәкаль-әйтемгә тартым берәмлекме ул, фәрдләр – икеюллык бәетләрме, өчьюллыклар, дүртьюллыклар, робагыйлармы – аларның үз эчендә дә төрле бүленешләр һәм төсмерләр яши. Шагыйрьнең дүртьюллыклары Рудакиның миниатюр драмаларына, Хәйямнең көтелмәгән чишелеш тәкъдим иткән новелла-робагыйларына охшаганнар да, охшамаганнар да. Аларда, урта гасыр Шәрык әдәбиятында бик популяр булган әдәб жанрлары традицияләренә таянып, үзебезнең милли мәнфәгатьләрне искә алып, рухи яңарышка чакыру, фәлсәфи-этик фикер әйтү көчле.

Әдәби традицияләр күзлегеннән караганда да, «Тере су» китабы күптармаклы: ул төрки-татарларның сүз сәнгате хәзинәсенә, Коръән тәгълиматына, Шәрык Ренессанс әдәбиятына, акыллы, хикмәтле сүз әй-түгә, фән-ни-фәлсәфи фикерләргә, әдәб жанрындагыча үгет-нәсыйхәт белән үрелгән рухи кыйммәтләргә нигезләнгән. Шуңа күрә автор үзе дә: «...Мин барлык кыйммәтләрне / Шигырь бизмәненә / Салып үлчим хәзер...» – ди.

Ислам мәдәниятенең үзәген тәшкил иткән төп кыйммәт – акыл. Мөселман фәлсәфәсе буенча да, Аллаһы Тәгалә иң элек акылны яраткан, диелә: «Әүвәлү мә халәкә Аллаһу әл-Акла». Акылның даими юлдашы итеп гыйлем, белем күрсәтелә. Акыл белән гыйлем үзенең тышчасы булган сүзләр ярдәмендә генә яши ала дип аңлатыла. Сүз сәнгате дигәндә, ислам дөньясында иң элек Коръән өйрәтмәләре күздә тотыла.

Шагыйрьнең газәл, робагый һәм гыйбарәләрендә Коръәннең асылын тәшкил иткән әт-Тәүхид (монотеизм) фәлсәфәсенә ихлас ышануны белдергән юллар байтак очрый. «Бар халыклар, илләр, галәмнәр өчен, – ди ул, – берәү генә бирдәнбер – Бер Хак Тәгалә – Аллаһы үзе генә». Шагыйрьнең «Тере су» китабындагы газәл лирикасы да, андагы гыйшык җырлары да, гарәпләрнең касыйдә жанрындагыча, Аллаһы Тәгаләгә мәдех укудан башланып китә: «Фатихасыз бер көнем дә торалмам, / Ил-көнемә иминлек бир, Бер Аллам. / Уң кыл юлын бөтен нәсел-ыруның, / Кодрәтең киң, рәхмәтең зур, Бер Аллам».

Дөньяны акыл һәм хисләр белән танып белергә юллар ачкан, рухи камиллек баскычларына күтәргән, бәхетле иҗат мизгелләре бүләк иткән Аллаһыга лирик герой бик тә рәхмәтле. Икенче бер газәлендә ул Бөек Кодрәт иясенең Коръән-Кәрим ярдәмендә гөнаһлы җир кешеләренең, тәүбә итеп, илаһият – рухи яңарыш юлына аяк басуларыннан хозурлык кичерә: «Коръән – бел – хаклык үрнәге бирдәнбер, / Раббым мәңгелек нурына төргәндер».

Күрәбез, газәл бик тә тирән эчтәлекле бәет белән ачылып китә. Иң элек анда Коръән тәгълиматының асылын олуг бер кыйммәт – хаклык, гаделлек мәсьәләсе тәшкил иткәнлеккә басым ясала. Дөрестән дә, мөсел-ман әдәбиятларының кайсысына гына мөрәҗәгать итмик, аларның һәрберсенең үзәгендәге төп мотив – гадел кеше, гадел патша, гадел җәмгыять. Бәетнең икенче шигъри юлы да мәгънәви яктан сыйдырышлы. Шагыйрь Коръән аша Илаһият тарафыннан җир кешеләренә иңдерелгән гаделлек идеалларының мәңгелек икәнле-генә дә басым ясый. Раббының

мәңгелек нурына төренгән бу «хаклык» төшенчәсе Изге китапның 24 нче сүрәсендәге «Аллаһ Күкләр һәм Җирнең нуры» дигән 35 нче аять белән дә аваздаш. Әмма автор Коръәндә яктылык квантлары (кисәкчәләре) – фотоннар турында чагылыш тапкан фәнни карашларга символик эчтәлек сала: ул адәми затларны гаделлек юлына өндәүче илаһи яктылык вазифасын үти башлый. Мәрхәмәте чиксез булган Аллаһыдан гөнаһлардан ярлыкау сорап ялварган газәлләр урта гасырларда бүген без робагый жанры остасы дип санаган Гомәр Хәйям тарафыннан да байтак иҗат ителгән, аларны мөселман татарлар да яратып укыган. Мөхәммәт Мирзаның алты бәеттән торган, «Коръән – бел – хаклык үрнәге бердәнбер» дигән мәгънәви ачкыч белән башланып киткән газәле,  – безнең уебызча, дини лириканың матур мисалы.

Изге китап күрсәтмәләренең кеше табигатен уңай якка үзгәртү һәм Илаһият капкаларын ачудагы әһәмияте күкләрдәге нәкышле яктылык балкышын хәтерләткән гарәп хәрефләре ярдәмендә хикмәтле сүз әйтүгә корылган гыйбарәләрдә ассызыклана: «Коръән, кяферлеккә киртә куеп, тәүбә иттереп, оҗмахка илтә...»

Иҗат психологиясен дә автор шагыйрьгә күкләрдән иңгән илһам – нур рәвешендә аңлата: «Шагыйрьнең китабы бераү генә була. Бөтен гомере буе язган барлык шигырьләренең иң асыллары, – Илаһының нурына манып язылганнары, тупланганы...» Илаһиятнең мәңгелек бер кыйммәте булган сүз сәнгате турындагы карашлар сигезьюллыкларда Низами һәм Котб поэмаларындагыча чагылыш таба: «Шигырь, дустым, Илаһының / Җанга биргән сулышы!» Бакыйлыкка күчкәндә дә, ул Илаһият нурларының үзенә юлдаш булуын тели: «Балкыт Илаһыдан килгән нурыңны, / Яктырт мәңгелеккә күчәр юлымны!»

Дини кыйммәтләр белән бәйле тагын бер мотив – шагыйрь иҗатының буеннан-буена төрле мәгънәви төсмерләрдә кабатланып килүче иман сафлыгы мәсьәләсе. Иман Аллаһы күрсәтмәләренә, пәйгамбәребез сөннәтенә турылыклы лирик геройның Җир йөзендәге имин яшәешен тәэмин итә: «Ил-йортым киң, ризыгым мул, рухым шат, / Юлым ачык – хилафсыз иманыма».

Милли-рухи яңарыш мәсьәләләрен хәл итү өчен дә, һәрдаим иман кирәк. Коръәндә кырыктан артык искә алынган «иман» төшенчәсе, аныңча, төрле бәла-казалардан – «шайтаннар, сихерчеләр, имчеләр хәйләсеннән саклану өчен иң үтемле чара». Дөньядагы матди байлыклар, бүген бар булып, иртәгә юкка чыгарга мөмкиннәр. Ә дингә ышану, иманлы булу – мәңгелек хәзинә: «Байлык – бер айлыктыр, / Ярлылык – гомерлек... / Адәм баласына / Бетмәс байлык – иман, / Оҗмахка керерлек». Шуңа күрә ул замандашларына да: «Каршылыйк / Киләчәкне якты өмет / Иман белән», – дип мөрәҗәгать итә.

Яшәү фәлсәфәсен бу рәвешчә Алла, Коръән тәгълиматы, «иман» төшенчәсе, шагыйрьгә Илаһияттән иңгән илһам кебек, тема-мотивлар тирәсенә туплап, милләттәшләребезгә дә дини-әхлакый, мәдәни таяныч һәм яшәү үрнәге итеп тәкъдим итү бүгенге татар әдәбияты өчен дә, Мөхәммәт Мирза шигърияте өчен дә яңа күренеш иде. Чынбарлыкта исә, бу – урта гасыр гарәп, фарсы, төрки әдәбиятларының төрле жанрларында киң таралыш тапкан, матур әдәбият белән фәлсәфә арасында торган куәтле һәм нәзакәтле әдәб жанрының яңа тарихи шартларда калкып чыгуы.

Мөхәммәт Мирзаның газәлләрендә дә полифоник яңгырашлы яшәү фәлсәфәсе өстенлек итә. Бер төркем газәлләрдә Алла, иман, күкләр һәм җир кешесенең җирдәге миссиясе, ахырзаман кебек эсхатологик темаларга бәйле кичерешләре чагылдырылса, икенчеләрендә, Коръәндәгечә, Илаһияттән ерагайта торган бозык гамәлләр – антикыйммәтләр турында сүз алып барыла; өченчеләре исә дөньяны ыгы-зыгылы, алыш-бирешле базар, бертуктамый әйләнеп торучы сәхнә-тамаша итеп күз алдына китереп бастыра; дүртенчеләрендә «вакыт» төшенчәсе һәм кеше гомере, ел фасыллары турындагы уй-кичерешләр бирелә; бишенчеләрендә дәүләте булмаган, «качып китмәс, баш күтәрмәс» эш аты булган кардәшнең түземлеге калмыйча, «Бәйнәлмиләл» җырына ишарә-аллюзия ясап, «Тор, күтәрел, милләт!» «бусагада яңа гасыр», «мең дә бер богауны өзеп орыйкмы» икән әллә дип, «төштән соң» гына акылга килгән татар кешесенең уйланулары бирелә. «Хәтердән чыкмас кара кан исе» һәм йөрәктә «йөз яра» калдырган Октябрь түнтәрелешенә дә иҗтимагый-сәяси эчтәлекле махсус газәл багышланган.

Саф мәхәббәт темасын яктырткан газәлләр Мөхәммәт Мирза лирикасында әллә ни күп түгел. Аларның булганнары да фарсы һәм төркиләрнең Ренессанс дәвере газәлләреннән нык аерыла. Анда суфичылык шигъриятендә киң кулланылышта булган, Алла белән берләшүне, кушылуны символлаштырган, йә булмаса, Хәйям, Хафизның дөньяви эчтәлекле робагый һәм газәлләрендәгечә, матур табигать кочагында сөйгән ярлар белән шәраб эчеп утыру кебек гедонистларча бирелгән һәм битарафлык, ваемсызлыкка өндәгән, ләззәтле җан тынычлыгына чакырган эпикурчылык мотивлары очрамый. Гашыйклыктан авыруга сабышу, ә аннан мәҗнүнгә

әйләнү халәтен гәүдәләндерү дә күзәтелми. Шагыйрьнең Аллаһының барлыгына һәм Берлегенә мәдех укыган, Коръән өйрәтмәләренә таянып, замандашларын рухи яңарырга чакырган газәлләре, әйткәнебезчә, XXI гасыр башы татар шигърияте өчен үзенә күрә бер ачыш булды. Дөньяви мәхәббәт темасына, мәсәлән, гомер юлдашына багышланган газәлләрдә дә интим хисләр әдәп-сафлык, итагатьлелек кысаларында садә, серле, нәфис «ап-ак җилкәнле кораб» образында чагылыш таба: «Татлыдан да татлырак ни җиһанда – / Учларыңнан чишмә суын эчкәндә!..» Сәнгатьчә фикерләүнең матур үрнәге булган мондый тыйнак сурәтлелеккә корылган бәетләрне шагыйрь газәлләреннән күпләп китереп булыр иде.

XX һәм XXI гасырлар аралыгында марксистик идеология белән бәйле карашларның әһәмияте юкка чыгу, Коръән тәгълиматы әйләнеп кайту аксиологик кыйммәтләргә игътибарны бермә-бер көчәйтеп җибәрде. Философлар гына түгел, башка гуманитар фән белгечләре дә, дәррәү кузгалып, рухи-әхлакый кыйммәтләрне өйрәнү эшенә керештеләр. Иҗтимагый-мәдәни яшәешебезнең көзгесе булган аксиологик кыйммәтләргә татар әдәбиятында да игътибар артты. Милли ихтыяҗларга җавап бирү максатын күздә тотып, татар һәм шәрык халыкларының акыл җәүһәрләрен иҗади эшкәртү нигезендә Мөхәммәт Мирзаның «Мең дә бер гыйбарә» исемле китабы дөнья күрде. 5 бүлектән, 31 бүлекчәдән торган, тематик принцип буенча оя-оя итеп тезелгән бу гыйбарәләр китабын аксиологик сүзлек дип кабул итәргә мөмкин. Алла – Кеше – җәмгыять триадасын, дөньяви һәм дини этика, әдәби иҗат психологиясе кебек бик күп мәсьәләләрне эченә алган бу чәчмә, ярым шигъри афоризм, хикмәтле сүз, мәкаль-әйтемнәрне парлы аксиологик кыйммәтләр күзлегеннән өйрәнү, безнеңчә, аеруча отышлы (мәсәлән, Аллага ышану – имансызлык; ата-ананы, туганнарны, кешеләрне хөрмәт итү – мин-минлек, тәкәбберлек, нарциссизм; яшәү – үлем; елау – көлү; бәхет – мескенлек; дуслык – дошманлык; тугрылык – хыянәт; миллилек – манкортлык; байлык – мохтаҗлык; юмартлык – саранлык һ. б.). Шул ук вакытта бу гыйбарәләрне Коръән өйрәтмәләренә туры килмәгән, Аллаһы Тәгалә кабул итмәгән антикыйммәтләр күзлегеннән дә барлап була (миһербансызлык, кяферлек, иблислек, усаллык, гайбәт сөйләү, хәйләкәрлек, комсызлык, куркаклык, ахмаклык, исереклек, ялкаулык, әрсезлек, хөсетлек, мәнсезлек, мактанчыклык, булдыксызлык, караклык һ. б.).

Гыйбарәләр жанры турында әдәбият белемендә төрле фикерләр әйтелгән. Берәүләрчә, чәчмә сүз белән язылып та, теге яки бу гыйбарә укучыда тирән уй-фикер һәм хис-кичереш уята икән, аны тулы хокуклы шигырь дип атарга кирәк. Икенче берәүләр, дөньяны танып белүнең бер төре булган мондый гыйбарәләр аңлатмалы сүзлек алымына карый, диделәр. Габдулла Тукай иҗатында, аеруча аның сатирасында, күләм ягыннан шактый зур урын алып торган бу жанр галимнәребез тарафыннан шул күзлектән чыгып өйрәнелде, дөнья әдәбияты тарихында бик күп язучыларның (мәсәлән, Сәгъди белән Заканиның) аңлатмалы сүзлек алымыннан оста файдаланганлыгы билгеләп үтелде. Кабат шуны ассызыклыйбыз: бу хикмәтле, фәлсәфи, канатлы афоризмнар, акыллы чәчмә һәм шигъри гыйбарәләр – урта гасыр Шәрык һәм татар әдәбиятларында тамырлары тирән булган, безнең заманда исә архетип булып үсеп чыккан күптамырлы әдәб әдәбиятының бер тармагы. Аурупа һәм рус әдәбият белеме күзлегеннән караганда, бу гыйбарәләрне XX гасырда пәйда булган постмодернистик әдәбиятның бер юнәлеше – концептуализм күренеше итеп тә карарга мөмкин.

«Гыйбарәләр» китабындагы «Һәр хәрефкә – бер фикер» циклы авторның аксиологик кыйммәтләр турындагы уй-фикерләренең һәм хис-кичерешләренең гәүдәләнеше булып тора. «Рухи кыйммәт – акыл белән җан диалектикасы» (Ибн Сина) дигән фикерне ул «р» хәрефеннән башланган «рух» төшенчәсе ярдәмендә түбәндәгечә аңлата: «Рух – кеше җанының, халыкның, кешелекнең халәте... Ул – ике дөнья арадашчысы... Рух үлемсез». Кеше рухының, рухи кыйммәтләрнең үлемсезлеге турындагы бу фикер һәр заман өчен аксиома вазифасын үтәүдән туктамаячак.

«Гыйбарәләр» китабында Аллаһы Тәгаләнең «Илаһи кәлям» балкышыннан нур алган иҗат әһелләре эшчәнлегенә, аларның җир кешеләренең рухын яңа-р-тудагы миссиясенә югары бәя бирелә. Мөхәммәт Мирза фикеренчә, «Чын Иҗат – Аллаһы рәхмәте һәм фатихасы, Аллаһы фатихасын алган иҗатчы – пәйгамбәр». Коръәндәге аерым сүрә һәм аятьләргә нигезләнеп, шагыйрьләрне пәйгамбәрләр белән янәшә кую урынлымы, әллә ширек эшме, бу турыда әледән-әле бәхәсләр дә туып тора. Авторның югарыда әйтелгән сүзләре дә шик-шөбһә тудырырга мөмкин. Әмма аның бу хакта үз фикере бар: «Шагыйрьне олылау һәм пәйгамбәргә тиңләү һич кенә дә икенчесен кечерәйтү түгел». Сүз сөрешен дәвам итеп, шагыйрь бу хактагы фикерен тагы да ачыклый төшә: «Пәйгамбәрләр мең елга бер генә туа. Үзеннән соң иҗаты йөз ел яшәгәннәр дә – пәйгамбәр!..» Бөтендөнья әдәбияты, шул исәптән шәркый мөселман әдәбиятлары тарихында да

«шагыйрь – пәйгамбәр» мотивы гасырдан-гасырга, сүз сәнгате осталарының буыныннан буынына, үзебезнең Р. Фәйзуллин, Р. Гаташ, М. Әгъләмов, Зөлфәтләргәчә даими рәвештә кабатланып килә.

Мөхәммәт Мирзаның кайсы гына китабына күз салсак та, аларның һәркайсында ул акыллы сүз әйтү ысулы белән халкы, милләте алдындагы җаваплылыгы турында сүз алып бара һәм һәрвакыттагыча шагыйрь-ләрнең иҗтимагый-мәдәни яшәештәге вазифасын пәйгамбәрлек миссиясеннән аерып карамый.

* * *

Мөхәммәт Мирза шигъриятенең югары ноктасы – «Адәм баласы» дип аталган бишьюллыклар бәйләме. Соңрак бу цикл төрле телләргә тәрҗемә ителеп, китап булып та басылып чыкты. Әдәбият сөючеләр аны гаҗәпләнү катыш зур кызыксыну белән каршы алдылар. Бу нинди шигырьләр? Татар шигърияте өчен алар ачышмы? Әллә кайчандыр булган, әмма бүген онытылган шигъри традицияләрне заманга ярашлы итеп, интертекстуаль алымнар белән яңартып кайтарып бирүме? Язучылар, әдәбият һәм фәлсәфә галимнәре бу хакта үзләренең игътибарга лаек байтак кына фикерләрен дә әйттеләр.

Күренекле шагыйрь һәм сәнгатькяр Ренат Харис бик хаклы рәвештә Мөхәммәт Мирзаның «Адәм баласы» шигырьләре тупланмасын ил, дәүләт, халыкның җитешсез яклары хакында «батыр йөрәкле» ирләрчә «кычкырып әйтелгән публичный сүз», татар шигъриятен энҗе-җәүһәрләр – яңа ачыш-казанышлар белән баеткан, аның үсеш дәрәҗәсен яңа баскычка күтәргән «үтә җитди әсәр» дип билгеләде (Мәдәни җомга, 2011, 8 апрель).

«Адәм баласы» циклына бәя бирүчеләрнең барысы да, аеруча сүз сәнгате тирбәлешләренә үтә дә сизгер булган шагыйрьләр, Мөхәммәт Мирзаның төрки-татарларның халык авыз иҗаты, ислам мәдәнияте, Шәрык классикасының үгет-нәсыйхәт белән сугарылган фәлсәфилек, фәннилек, чичән-акыннар, ашуг-бахшыларча хикмәтле, акыллы сүз әйтү традицияләренә тугрылыклы булып калуын, аларны танымаслык итеп иҗади яңартуын уңай бәяләделәр. Чыннан да, бишьюллыклар шигъри бәйләменең тематикасы, проблематикасы гаять тә киң, аларда чагылыш тапкан фәлсәфи-эстетик, әхлакый-этик мотивлар саны да бихисап. Шагыйрь Шамил Маннапов әйткәнчә, Мөхәммәт Мирза үзенең бишьюллыкларында беркемне дә кабатламый, вакыт-пространство чикләрен дә киң ала, адәм баласының Җир йөзендәге яшәешен, «дөньяга килешеннән үлеменә кадәр, Җирдән Күкләргә кадәр араны сыйдыра» (Мәдәни җомга, 2011, 11 февраль).

Әдәбиятчы Фәридә Хәсәнова рус һәм татар тел-ләрендә басылган хезмәтләрендә бу оригинал бишьюллыкларның строфа төзелешендә япон танкасы жанры чалымнарын тапты. Философ Айдар Юзиев исә аларның Шәрык әдәбиятларындагы әдәб жанрындагыча фәлсәфи-дидактик фикер йөртүгә нигезләнгән-леген ачыклады (Звезда Поволжья, 2012, 31 марта – 6 апреля). «Адәм баласы» китабындагы шигырьләрдә күтәрелгән мәсьәләләр, аларның әдәби-эстетик һәм этик табигате, жанры һәм строфа үзенчәлекләре турында бу мәкалә авторы да озак уйланды, Евразия халыкларының шигырь төзелешенә караган байтак хезмәтләр белән танышты.

Коръән өйрәтмәләре һәм ислам дине мифологиясе буенча, Адәм – җирдәге беренче Кеше һәм пәйгамбәр. Шайтан коткысы аркасында Адәм белән Һава, Аллаһы кисәтүләрен онытып, үлемсез булабыз дип, тыелган мәңгелек агачы җимешләрен ашыйлар, шул сәбәпле оҗмахтан куылалар, авыр сынауларга дучар булалар. Мөхәммәт Мирза иҗади шәрехләгән Адәм исә – кешелек җәмгыятенең җыелма образы.

Кешеләрне рухи камиллеккә чакыру, иҗтимагый һәм көндәлек яшәештә яңарырга өндәү – «Адәм баласы» китабының әйдәп баручы бер мотивы. Шуңа күрә дә аны урта гасырлардагы Шәрык һәм татар әдәбиятларыннан XXI гасырга әйләнеп кайткан, патшалардан башлап сарай хезмәтчеләренең һәркайсы белергә тиеш әдәб әдәбияты традицияләренең Мөхәммәт Мирза иҗатында иҗади чагылышы дияргә мөмкин.

Шагыйрь «Адәм балалары» циклының үзәгенә изгелек һәм явызлык турындагы рухи кыйммәтләрне куя. Бишьюллы строфаның кыл уртасына Коръәннең 7 нче сүрәсендәге 26–27, 31, 35 нче аятьләрдә рефрен кебек кабатланган, гарәпчә «Йә-ә бәнии Адәмә» анафорасыннан алынган, татарчага «Адәм баласы» дип үзгәртелгән рефренны урнаштыра. Әмма академик М. Б. Пиотровский бу стилистик чараны анафора дип түгел, рефрен дип атый.

Гомумән алганда, Мөхәммәт Мирзаның «Адәм баласы» циклындагы алтышар иҗекле бишьюллыклар турында түбәндәге нәтиҗәне тәкъдим итәргә мөмкин: сәнгатьчә фикерләүнең яңалыгы белән укучыларның игътибарын җәлеп иткән, акыл-гыйлем культына корылган бу шигырьләр – гарәп-фарсыларның, төрки-татарларның дүртьюллыкларыннан,

робагыйларыннан, мөрәббәгъләреннән үсеп чыккан, кешелек җәмгыятенә «адәм балалары» дигән шигарь-мөрәҗәгать белән матур билбау сыман строфа уртасына кереп утыртылган, моңарчы шигырь язу практикасында һәм теориясендә күзәтелмәгән рефренның яңа төре һәм дә зур гомумиләштерү көченә ия булган, Коръән тәгълиматына таянып, рухи яңарыш идеяләрен, гомумкешелек кыйммәтләрен алга сөргән, гуманистик эчтәлекле, фәнни, фәлсәфи-эстетик, этик зарурияталәрне чагылдырган уникаль жанр һәм авторның олы ачышы.

Мөселманнарның үгет-нәсыйхәт белән бәйле әдәб әдәбияты традицияләренең һәм интеллектуаль башлангычның көчле булуы «Адәм баласы» циклындагы бишьюллыкларның эчтәлеген аңлауда киеренкелек тә тудырырга мөмкин. Гадәттә, мондый шигырьләр гасырлар алмашканда, дөньяга карашлар үзгәргәндә мәйданга чыга. Нәкъ менә шундый хәл XX гасыр башы татар әдәбият белемендә күзәтелгән һәм «Тукай шагыйрьме, түгелме?» дигән бәхәсләргә сәбәп булган иде. Дөньяны танып белүнең һәм сәнгатьчә гәүдәләндерүнең йә акыл, йә хис культына өстенлек бирү, йә булмаса, аларның һәр икесен дә аерылгысыз бербөтен итеп синтезлап, Гомәр Хәйям кебек үлемсез робагыйлар тудыру бөтендөнья әдәбиятының буеннан-буена дәвам итә. Шуңа күрә дә фарсы Яңарышының даһи шагыйре һәм гуманисты Сәгъди Ширазины, салкын вәгазьләр сөйләүче, акыл сатучы дип, мөселман неоплатоникларыча, мәхәббәт, табигать, шәраб культын мак-таган Гомәр Хәйямгә һәм дә гүзәл хисси газәлләр авторы Хафиз Ширазига, йә булмаса, татарның «мәхәббәт мәҗнүне» Рәдиф Гаташка каршы куйсак, һич кенә дә гадел адым булмас иде. Шуңа күрә тән – җан – акыл бәргәләнүләрендә туган, сүз сәнгатенең патшасы булган шигърияткә (Абай) һәрдаим игътибар һәм ихтирам сорала. Мөхәммәт Мирзаның да: «Биш юлым – биш гөлем, / Сугарып үстердем. / «Адәм балаларым» / Ташлап китмәс, шөкер, / барысын үз күрдем...» дигән лирик җылылык белән өртелгән юлларын да шундыйрак мәгънәдә кабул итәргә кирәк.

* * *

Тирән фикерле, полифоник яңгырашлы «Адәм баласы» шигъри бәйләме – Мөхәммәт Мирзаның гына түгел, гомумән, XXI гасыр башы татар поэзиясенең зур уңышы. Бу – әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан бирелгән гомуми бәяләмә. Шагыйрь Равил Бохараев М. Мирза бишьюллыкларының төрекчәгә, русчага һәм инглиз теленә уңышлы тәрҗемә ителүенең сәбәбен әткәй-әнкәйләребез дога кылган туган телдә язылуында һәм универсаль эчтәлекле булуында күрә. «Переводя лишь такие стихи, которые на родном языке имеют универсальное, понятное всем народам звучание... я убедился, что пятистишия Мухаммата Мирзы действительно ясно и внятно звучат на языке Шекспира и Байрона» (Звезда Поволжья, 2011, 7–13 апреля). Шуңа күрә, аныңча, Ричард Маккейнның тәрҗемәләре барлык аурупалылар өчен дә ачык аңлаешлы.

«Адәм баласы» циклының универсаль эчтәлекле булуы аны иҗат ысуллары, әдәби традицияләр һәм бәйләнешләр җәһәтеннән дә ике канатлы иткән. Бер яктан, ул архетиплар вазифасын үтәүче төрки-татарларның паремияләренә (мәкаль-әйтемнәренә), мөселман әдәбиятларының әдәб жанры традицияләренә барып тоташса, икенче яктан, М. Мирза, төрле мәдәниятләр кисешкән җирлектә яшәгән шагыйрь буларак, Көнбатыш һәм рус әдәбиятындагы постмодернизм өчен хас әдәби-эстетик юнәлешләр – концептуализм һәм экзистенциализм белән дә тыгыз бәйләнешкә керә.

Фәнни-фәлсәфи фикерләрне, әхлакый сентенцияләрне синтезлаган, интеллектуальлеккә, сизелер-сизел-мәс яшерен иониягә корылган, шигъри форма һәм өслүбтә оригинальлеккә омтылган, интертекстлардан мул файдаланган, идеяләр әдәбияты дип аталган концептуализм үзенең байтак үзенчәлекләре белән гарәп-фарсы-төркиләрнең әдәб жанры хосусиятләрен хәтерләтә. Америка һәм Аурупаның концептуалистлары да, – шигъриятебездәге бүгенге яңа шәркыйчелек тарафдарлары кебек, үткәнгә әйләнеп кайтып, бигрәк тә борынгы әдәби алымнарны яңартып, әдәби барышта алга таба хәрәкәт итүчеләр.

«Адәм баласы» циклының универсальлеге аны постмодернистик әдәбиятның икенче бер юнәлеше – экзистенциализм белән дә бәйләп өйрәнүгә мөмкинлек бирә. Яшәү фәлсәфәсен чагылдыручы экзистенциализм – бөтендөнья әдәбиятының мәңгелек бер темасы. Ул урта гасырларда да, яңа заманда да киң кулланышта булган. Гадәттә, экзистенциаль философия һәм әдәбият гасырлар алмашкан, идеологияләр үзгәргән чорда мәйданга чыккан. Мәсәлән, тирән кризис кичергән, потларга табынып җаһиллектә яшәгән, әхлакый бозыклыклар сазлыгына баткан бәдәви гарәпләр арасында рухи инкыйлабка тиң ислам диненең мәйданга чыгуы, экзистенциаль мотивлар белән сугарылган Коръ-ән тәгълиматының, әт-Тәүхид фәлсәфәсенең гамәлгә керүе – шундый зарурияҗләр нәтиҗәсе.

Модернестик әдәбиятның бер тармагы булган экзистенциализм XX гасыр башы татар әдәбиятын да читләтеп үтмәде. Шәхес һәм милләт язмышына нисбәттә яшәү фәлсәфәсе Дәрдемәнд, С. Рәмиев, М. Хәнәфи кебек романтиклар иҗатында тирән сәнгати чагылыш тапты. СССРның таркалуы, ислам мәдәнияте казанышларының торгызылуы XX гасыр азагы – XXI гасыр башы постмодернизм әдәбиятына экзистенциаль юнәлешнең кабат әйләнеп кайтуы өчен уңай җирлек тудырды. Фәүзия Бәйрәмова әсәрләрендә, Айдар Хәлим публицистикасында дәүләтчелегебез тарихына, Россиянең колониаль сәясәтенә, милли-азатлык хәрәкәтенә, милли яшәешебезгә үткен һәм кискен экзистенциаль анализ ясалды. Узган гасыр азагында дөнья күргән Мөхәммәт Мирза шигырь-поэмаларында да Россия идарәчеләренең рус булмаган милләтләрне изү сәясәтенә көчле ризасызлык яңгырады. Ә менә «Адәм баласы» китабындагы бишьюллыкларда ислам диненең асылына туры килмәгән көч куллану, гыйсъянчылык мотивлары алып ташланды. Ни өчен моның шулай икәнлеген автор үзе дә шәрехләп үтә: «Дин фәлсәфәсен, тәгълиматын чын-чынлап кабул иткән бер генә кеше дә, нинди милләттән һәм нинди җәмгыятьтә яшәвенә карамастан, агрессивлык, экстремизм кебек күренешләрне һичкайчан кабул итмәячәк» (Мәдәни җомга, 2011, 7 гыйнвар).

Билгеле, экзистенциализм әдәбияты төсмерләргә бай. Аның радикаль агымнары да, чынбарлыкка сән-гатьчә мөнәсәбәтне дини күзлектән, йә булмаса Аристотельнең «алтын урта» кагыйдәсе буенча яктырткannары да бар. Экзистенциализм әдәбиятында яшәү фәлсәфәсенең кайсы яклары күбрәк чагылыш таба дигән сорауга атаклы философ Никола Аббаньяно болай дип җавап бирә: «...литература, названная экзистенциалистской, стремится подчеркнуть наименее респектабельные и наиболее грустные, мрачные события человеческой жизни...» (Введение в экзистенциализм. – Санкт-Петербург, 1998, – С.455). Әмма Мөхәммәт Мирзаның адәм балалары яшәешендәге вакыйгалар, мәшәкатьләр, кылган гамәлләр сызлану, борчылу, рефлексив вөҗдан газаплары, шөбһәле уй-фикерләр чыганагы гына түгел. Ул Кеше дигән затның ялгыш адымнарын тәнкыйть итү белән генә чикләнми. Шагыйрь киләчәктә адәм балаларының авыл, шәһәрләр төзеячәгенә, әдәпле, әхлаклы мәдәни тормыш корачагына, галәм серләренә төшенәчәгенә, шәхеснең дәрәҗәсе югары бәяләнәчәгенә («Бер кеше – бер галәм»), җирдәге тереклекнең дәвам итәчәгенә, аның Аллаһы Тәгалә бүләге икәнлегенә ихлас ышана. Мондый өмет-хыяллар «Адәм баласы» тупланмасының кырыс реализмын лирик җылылык һәм романтик төсмерләр белән баета.

Нәтиҗә рәвешендә шуны әйтергә мөмкин: йөз-ләгән тема, проблема, мотив, миниатюр сюжетларны берләштергән,ербөтен итеп оештырган, акыллы сүз әйтүгә корылган өр-яңа шигъри архитептоникага нигез салган, яшәү фәлсәфәсен, рухи кыйммәтләр мәсьәләсен үзәккә куйган универсаль эчтәлекле «Адәм баласы» циклы – Шәрык һәм Гареб әдәбиятлары өчен хас дөньяга карашларны, иҗат ысулларын, жанрларны бергә очраштырган, синтезлаган уникаль күренеш, шагыйрь Мөхәммәт Мирзаның ихтирамга лаек иҗади ачышы.

*Резеда Ганиева,*
филология фәннәре докторы

* * *

Чиксез мәңгелектә
Тыгыз янәшәлек...
Адәм баласының
куышы – газиз җир,
оҗмахтай яшәрлек...

* * *

Хәрәкәт – бәрәкәт,
уйлаган төшенер...
Адәм баласына
түшәмгә төкереп
яту да бер шөгыль...

* * *

Түрдән гүргә төшәр,
убылыр ләхете...
Адәм баласының
туфрак булыр төше –
мәңгелек тәхете...

* * *

Кояштагы таплар
чынында болыттыр...
Адәм баласы үз
мантыйгына каршы
барысын онытыр...

* * *

Балкый да сүнәдер,
атылганда, йолдыз...
Адәм баласының
күпмесе күрәдер:
күкләр дә тынгысыз...

* * *

Йозак – күренгәне,
тозак – төренгәне...
Адәм баласының
кисәтеп торуы...
читкә үрелгәнне...

* * *

Дугада кыңгырау
чыңы юл саптырыр...
Адәм баласының
атлысы барыбер
затлысын таптырыр.

* * *

Бәгыре – үзәктә,
Җаны – тамырында...
Адәм баласының
гомер агачына
җайсыз кагылына...

* * *

Атылды да чумды
төннең карасына...
Адәм баласын да
төшендерү фарыз
шунда барасына...

* * *

Котылгысызлыкның
үтемле үрнәге...

Адәм баласының
җиде аршын кәфен
мәңгелек күлмәге...

* * *

Өсте-асты – мәңге,
ян-ягы үзгәрер...
Адәм баласының
Атлантидасының
җуелган эзләре...

* * *

Күренгәнен күрер,
күзаллар калганын...
Адәм баласының
күләгәсендәме
күренмәс ялганы?

* * *

Потка орыныр да
тагын гөнаһ кылыр...
Адәм баласының
чукынмаганнары
гыйбрәт алып торыр...

* * *

Маймыл: «Бабаңмын», – дип
утырды башына.
Адәм баласының
ышанганын күреп
төкерде ашына.

* * *

Ил-көнгә керәге
җәя бөгәлгәндә...
Адәм баласының
базары үзенә
бәя бирәлгәндә...

* * *

Эзләп йөрмәсә дә,
үзе килеп баса...
Адәм баласының
түр тәрәзәсенә
гүр пәрдәсен аса...

* * *

Ботак буталыр да,
бөтенлек – тамырда.

Адәм баласына
җиде буынының
тамырын таныргa...

* * *

Уеның яманын,
сүзенең ялганын
Адәм баласының
күрдеңме үзендә
сизеп оялаганын...

* * *

Ап-ачык галәмнең
сере ачылмаган...
Адәм баласының
нәфесеннән куркып,
аны качырганнар...

* * *

Яктылык мәңгелек
түренә җиткерер...
Адәм баласының
күккә йөз чөйгәне
гүренә тиз керер...

* * *

Исем – үзгәлек тә,
исем – истәлек тә...
Адәм баласының
кушаматы исә
аслы нисбәлектә.

* * *

Ят ихтыярына
карусызлыгында
Адәм баласы үз
рухы егәрлеген
җую сызыгында...

* * *

Туганын күпсенгән,
дусларын ятсынган
Адәм баласының
нәфесеннән гайре ни
бар соң дөньясында...

* * *

Туа-тумышыннан
туймый кан коештан...
Адәм баласының

аяусызлыгына
шайтаны сыешкан...

* * *

Тәненә ябылгач,
туенгач тамагы,
Адәм баласы гел
ач-ялангачларга
чирканып карармы?

* * *

Бар көндәш дигәне,
бар сердәш дигәне...
Адәм баласының
һәр икесе бергә
бәгъренә тигәне...

* * *

Бәхет – дәүләт милке,
бәхет – Ходай ирке...
Адәм баласының
дәүләтсезлеге нәкъ
бәхетсезлек инде...

* * *

Җыелып барганы,
җыелып калганы...
Адәм баласының
үзен күмәр беркөн
чыгарып салганы...

* * *

Бүредән башлана
биләмә бүлеше...
Адәм баласының
биләмәсезлеге
бүреләр эшеме?

* * *

Чәче сирәгәя,
кашы калыная...
Адәм баласы соң,
шуннан качыйм диеп,
башын тыксын кая?

* * *

Алтыда тапканы
алтмышына җитәр...
Адәм баласы үз
чарасызлыгына

ис-акылы китәр...

* * *

Ни бары хаҗәте,
гамәле көчендә...
Адәм баласының
энҗедәй тешләре
елмаер өчен дә...

* * *

Күршенекен күрер,
үзенекен корыр...
Адәм баласының
эш кырганын күреп,
шайтаны котырыр...

* * *

Божрасы – арбага,
бөккәне – чанага...
Адәм баласының
туры китерүе
чарасын чамага...

* * *

Җил – карусыз ата
азаган бозыкмы?
Адәм баласының
үзенең ялганы
үзенә кызыкмы?

* * *

Әхлагы сагында
таләпнең катысы...
Адәм баласының
һаман саен кирә
тыйганны татыйсы.

* * *

Уеннан уймагы
чыгып кына торыр.
Адәм баласының
тыелганга һәрчак
нәфесе котырыр...

* * *

Күренеп торса да, –
күрми калганы хуп.
Адәм баласының

күрәләтә утка
керми калганы хуп.

* * *

Сандыгына барсы
саналып салынган...
Адәм баласының
соңгы сәламенә
сагышы сарылган...

* * *

Көзен коя, язын
кабат бөреләнә...
Адәм баласының
яфрак гомерендә
ыруы төрләнә...

* * *

Бер булса – тансыкка,
ун – талымсызлыкка...
Адәм баласының
барсы да дучармы
кабыргасызлыкка?..

* * *

Сорап килгәннәре...
Алып биргәннәре...
Адәм баласының,
бар күзен йоммыйча:
«Таптым», – дигәннәре.

* * *

Берсе – яшь түккәндә,
берсе – сөенгәндә...
Адәм баласының
ишенә күкләрдә
нәфрәт төенләнә.

* * *

Холкы, гадәте дә...
Бәлки, халәте дә?
Адәм баласының
юк тоз сипмәгәне
җан җәрәхәтенә...

* * *

Битләре саргайган,
язулары тузган...

Адәм баласының,
шул иске дәфтәрдәй,
гомерләре узган...

* * *

Алманың корты да
күченеп килгәнме...
Адәм баласына,
кирәксә, бер сәбәп
булырмын дигәнме?

* * *

Дулкын – галәмнәрнең
мәңгелек бер хәле...
Адәм баласының
күңле галәмендә
тибрәлә ни гаме?

* * *

Чиксез бу далада
сихерле җил дулый...
Адәм баласы, ник
хәерчегә һәрчак
җил каршы, дип уйлый...

* * *

Маңгаенда күзе
ачыла, ябыла...
Адәм баласына
кирәген күрмәскә
сәбәбе табыла.

* * *

...Кайнап тулып пеште
сөңге бозда тамчы...
Адәм баласының
йөзен ярып төште
тозлы яше – камчы...

* * *

...Таш кыя – вакытның
туктап калган хәле...
Адәм баласының,
ташны ташка бәреп,
ут чыгарган мәле...

* * *

Чәчәге – чәнечке...
Яфрагы – ут энә...
Адәм баласының
теленәсе күңле

шул гөлгә үреlә...

* * *

Төш – җисем үзәге,
матди күренеше...
Адәм баласының
килү-китүе дә –
төше бүленеше...

* * *

...Тапканыннан артык
һични югалтмаган...
Адәм баласының
күрәсен күрәчәк
пәрдәсе каплаган...

* * *

Үткәнгә – салават,
килерен – күрәчәк...
Адәм баласы үз
битарафлыгына
тилереп үләчәк...

* * *

Тауны урап үткән –
үтә дә зирәктер...
Адәм баласының
кыя-тау кичкәне
барыбер кирәктер...

* * *

Ни булса хәбәрнең
сәбәби асылы –
Адәм баласына
һәрчакта кисәтү
икәне ачылыр...

* * *

Гарасаттан калды
хәрабә өеме...
Адәм баласының
ил-көне хәерле
догада идеме?!

* * *

Тереклек суы дип,
шайтан сузган хәмер...
Адәм баласының
йотып җибәргәч үк

ирешкәне – кабер...

* * *

Садакта – ук җиде,
ян-якта – алмаш ат...
Адәм баласының
яулап алган җире
оныкларына ят...

* * *

Сала, кала корган,
чуен, тимер койган...
Адәм баласына
тәкъдир: «Мәңге эш!» – дип,
тәгаенләп куйган...

* * *

Үзе таңнан эштә,
акылы төштән соң...
Адәм баласының
кайчан, кайда, ничек
авызы пешкән соң?

* * *

Бер кат кисәр өчен,
җиде кат үлчәгән...
Адәм баласының
җиде буыннан
мирасы күчмәгән...

* * *

Күкләр сабак бирә...
Төшенгән төшенер...
Адәм баласына
тормыш – ватып алыр
чикләвек төшедер.

* * *

«Мин мин микән?!» – диеп,
өнендә саташкан
Адәм баласының
күзен ачтырыгыз
әүвәле иң баштан.

* * *

Саф алтыннан табут,
күпме яткан сыеп...
Адәм баласының

җанын күрмәкчеләр,
сөякләрен җыеп...

* * *

Бүредән курыкып,
урманга бармаган...
Адәм баласының
учак тергезерлек
чырасы калмаган...

* * *

Телнең сөяге юк,
кәгазьнең теле юк...
Адәм баласының
тел сындырып сөйләп
язмаган көне юк.

* * *

Җылы сүзе – җанга,
суыгы – йөрәккә...
Адәм баласының
дәшми торуы да
барыбер йөдәтә...

* * *

Телдән-телгә китә,
урап кайтып җитә:
Адәм баласының
авызы әйткәнне
колагы ишетә...

* * *

Телдән татлы тел дә,
сүздән шакшы да сүз...
Адәм баласының
телен тешләп әйтми
калганы – затлы сүз...

* * *

Тел яшергән кем дә,
телен болгаган кем?
Адәм баласының
тел тегермәненнән
онын урлаган кем?

* * *

Буе бер карышның
сакалы биш карыш...
Адәм баласының
юкса һәммәсенә
шул гыйбарә таныш?!

* * *

Кояшлы иртәдә
ызгыш-талаш корган
Адәм баласының
бәхетен киртәләп,
шайтан тозак корган...

* * *

Әткәң – туган илең,
әнкәң – туган ояң...
Адәм баласына
көн дә бер әйтерем:
– Хет шулардан оял.

* * *

Гарасат авылны
туздырып бетерде...
Адәм баласының
гомергә җыйганы –
давылга бер көнлек...

* * *

Юрганына карап
аягын сузмаган
Адәм баласының
юраган тормышы
хыялдан узмаган...

* * *

Акылсыз батырлар...
Хәерче тыйнаклар...
Адәм баласының
нихәтле холкына
шулкадәр үрнәк бар...

* * *

Яшен яшәгән дә –
ашын ашамаган...
Адәм баласына
ни дип дәшәргә дә
белми аптыраган...

* * *

Тәүбә итмәс борын...
Җәзадан котылган...
Адәм баласының
калган гомеренең
кояшы тотылган...

* * *

Бергә тулмаса да,
мең йөзгә таркала...
Адәм баласының,
нәфсе туймаса да,
йөз-бите тар кала...

* * *

Кершән ягып кына
алсуланмас йөзе...
Адәм баласының
җәе үтмәс борын
килеп баса көзе...

* * *

Сөяксез тел һәрчак
артыгын сөйләгән...
Адәм баласының
кәкере каенга
аркасын сөягән...

* * *

Талап тапканына
ташкала кордырган
Адәм баласының
ике йөз елдан соң
нәселе корыган...

* * *

Йөзем, хөрмә мулдан,
хурлары, бакчасы...
Адәм баласының
шул рәхәттән качып
китмәкче барчасы?

* * *

Әдәп, әхлак – нидән,
мәдәният – кемнән?
Адәм баласының
шәрә гәүрәтенә
яфрак япкан көннән!..

* * *

Кирәксә – табыла:
һәрнидән хәбәр бар...
Адәм баласына
искәртеп куелган
хәләл бар, хәрам бар...

* * *

Төшеп калганы бар...

Табып алганы бар...
Адәм баласының
гомергә берсенә
генә тарганы бар...

* * *

Сый – хөрмәт асылы...
Сыйдан зур булмый тор...
...Адәм баласының
хөрмәтсез сыена
кулыңны сузмый тор...

* * *

Ярлы-ябагайдан
Ришвәт ала табиб...
Адәм баласының
нәфсе-кәсебендә
рухы кала гарип...

* * *

Базарда бар да бар,
югы яшерелгән...
Адәм баласының
тыелган товары –
намус әҗереннән...

* * *

Тормыш – тоташ базар:
гел алыш-бирештә.
Адәм баласын да
сатып алып була
бәһасез килеш тә...

* * *

Кайгы гына түгел,
шатлык та елата...
Адәм баласы гел
шатлыктан шашыныр
көнен көтеп ята...

* * *

Авылда бер сәрхуш,
авылда бер тиле...
Адәм баласына,
гыйбрәтләнер өчен,
шулар җитә иде...

* * *

Яшәү – мәгънә эзләү,
касәсе тулыдыр.

Адәм баласының
җавабын табар җир –
Киек Каз Юлыдыр...

* * *

Җанын тойган гына
илаһи иҗатта...
Адәм баласының
нәфсен тыйган гына
савап-иҗтиһатта...

* * *

Фаразында дөнья
барыбер бетәчәк...
Адәм баласының
ярлыкагылганы
шул көнне көтәчәк.

* * *

Газраил-фәрештә
килер, ул – гамәлдә...
Адәм баласының
шәмдәлендә гомре
янып беткән мәлдә...

* * *

Беренче буразна –
ирне ир иткәне...
Адәм баласының
бөтен гомеренә
фәтвасы җиткәне...

* * *

Кипкән чүл елгасы,
ярын какмый дулкын...
Адәм баласының
гомер дәрьясын да
күмеп китәр бу ком...

* * *

Алыш-бирешендә
рибага бармаган
Адәм баласының
җиде буынының
табары – май да бал.

* * *

Нәселе-ыруы
көненнән киселгән
Адәм баласының

бар кылган гамәле
Иблис исеменнән...

* * *

Орлыгы – яралгы,
карындык түрендә...
Адәм баласының
тәкъдире ни язган –
шунда ук күренә...

* * *

Авыз пешә торыр,
һаман көтә торыр...
Адәм баласының
шуңа төшенгәне
төшеп этә торыр...

* * *

Җәйнең кыл уртасы...
Күкне тургай сарган...
Адәм баласының
күңел күзе алма-
сында сурәт калган...

* * *

Яман сүз өшетер,
Мактау сүз эретер...
Адәм баласының
тел төбендә йөрер
бер кашык дегете...

* * *

Язганы – аңар гел:
сүтәр дә ямар гел...
Адәм баласының,
ятлар йөген тартып,
гомере янар гел...

* * *

Саннар асылында...
Галәмдә бүленеш...
Адәм баласының
җирдәге тормышы –
иң серле күренеш...

* * *

Вөҗданы ирекле,
элмәк муенында...
Адәм баласының
очын-очка ялгау –
яшәү уенында...

* * *

Хәерле сәгатьтә
хәвеф-хәтәр чигәр...
Адәм баласына
саваплы гамәлдә
иман нуры иңәр...

* * *

Бер кеше – бер галәм:
артык йә аз түгел...
Адәм баласының
күңеле шуңардан
кимгә разый түгел...

* * *

Аллаһы: «Бул!» – дигән...
Җиргә инсан иңгән...
«Адәм баласына
санынча бирермен,
нәфсен тыйсын!» – дигән.

* * *

Гөлләрдән гөл матур,
Таулардан тау биек...
Адәм баласының
башы күккә тияр,
бай бүреген киеп...

* * *

Кайгысы китүгә,
Бәхеткә кинәнер...
Адәм баласының
биргәне – дөя дә,
алганы – энәдер...

* * *

Үткәннән көткәне
барыбер кадерле...
Адәм баласының
җан атып көткәне –
бары бер кабердер...

* * *

Ятагыннан ары
берни яратмаган
Адәм баласына
Ай икенче ягын
бер дә каратмаган...

* * *

Хәер-шәфкатьлелек
сатылмый базарда...
Адәм баласының
бары бер тарганы
бар, диләр, аңарда...

* * *

Давыл-гарасат та
Каза салмый үтә...
Адәм баласына
ачуын басарга
шушы мисал җитә...

* * *

Тыйнакның тыны юк,
күкрәп чыкмас бер дә...
Адәм баласының
чынлап эш кырганы
күкрәк сукмас бер дә...

* * *

Хәергә тарыган –
кемдер шәфкатендә...
Адәм баласының
саваплы хәере
Ходай рәхмәтендә...

* * *

Хәерне биргәне...
Хәерне алганы...
Адәм баласының,
хәер көтә-көтә,
таякка калганы...

* * *

«Мин-мин»нән артмаган,
үзен дә тапмаган
Адәм баласы гый-
брәтләнер өчен, үз
көзгесен каплаган...

* * *

Сукмакны – бер кеше,
юлны халык сала...
Адәм баласының
узган бар гомере
шунда яглып кала...

* * *

Канга-кан – мәгълүм үч...

Китап җавабында:
Адәм баласының
үчтән чигенгәне
хәер савабында...

* * *

...Әтәч сугыштыр да
таракан узыштыр...
Адәм баласының
тамагы туйгачтын
уе – азып-тузыштыр...

* * *

Чиксез галәмдә дә
барысы бүленгән...
Адәм баласының
галәмдәге юлы
бәйле үлеменнән...

* * *

Күк – Җир арасында
бернинди ара юк...
Адәм баласына
шул арасызлыктан
чыгарга чара юк...

* * *

Эзе – йөргәненнән,
эше – кылганыннан...
Адәм баласының
җирдә калганы ни
йөз ел торганыннан?..

* * *

Әҗәлдән дәвасын
эзләгән, тапмаган...
Адәм баласының
аяк астындагын
табаны таптаган...

* * *

Тик чиләнгәч арты
иярләгән атын...
Адәм баласының
вата-вата табар
чикләвеге каты...

* * *

Корыган агачка
кош оя кормаган...

Адәм баласының
хак имандагысы
потка баш ормаган...

* * *

Сугышта тапкан мал
барыбер таланган...
Адәм баласының
иле-ыруының
әхлагы каралган...

* * *

Урманны юк итте
саранча өере...
Адәм баласының
сулышы санынча
җирдәге гомере...

* * *

«Син» дигәндә тимәс...
«Мин» дигәндә тияр...
Адәм баласының
иреннәре әйткән
күңеленнән иңәр...

* * *

Сукырдан яшь чыгар,
чын-чынлап еласа...
Адәм баласы бай –
тумаган колыны
белен сындырмаса...

* * *

Хеопс өйгән таштан...
Аксак Тимер – баштан.
Адәм баласының
һәр пирамидасы
кан-яшькә буташкан...

* * *

Уйдан уй туадыр...
Уйны уй куадыр...
Адәм баласының
уйлы тормышы да
уеннан торадыр...

* * *

«Аһ!» дигәнче, күкне
айкап үтте яшен...
Адәм баласының

күзләренә багып,
күк түкте күз яшен...

* * *

Сүздән ботка пешәр,
ашап кына булмас...
Адәм баласының,
буш вәгъдә тыңламый,
бер көне дә узмас...

* * *

Хәмер – дәва, имеш:
кан-тәнне яздыра...
Адәм баласының,
зиһенен чуалтып,
күңелен аздыра...

* * *

Күленең – кипкәне,
Урманы – корганы...
Адәм баласының
утырган ботакка
балтасын органы...

* * *

Намазга басмаган...
Сәҗдәгә китмәгән...
Адәм баласының
тәне тойган рәхәт
җанына җитмәгән...

* * *

Ходайдан бүтәнгә:
– Колыңмын! – димәгез...
Адәм баласына:
– Тәүбәгә килергә
соңардың, – димәгез.

* * *

Яфрак селкенмәгән
тып-тын бу иртәдә
Адәм баласының
җиде күк катында
көнен хәл итәләр...

* * *

Ничек карасаң да,
ай йолдыздан якты...
Адәм баласының
тартып сузганы да
айдан айга чаклы...

* * *

Буйсыну фарыз дип,
кемдер алдаганмы?
Адәм баласының
җәя тарттырырлык
хәле калмаганмы?..

* * *

Бер сүз дә кирәкми,
ниләр әйтсәң дә аз...
Адәм баласының
ипсез бу иленең
килере – инкыйраз...

* * *

Кичелмәгән дәрья...
Күчерелмәгән тау...
Адәм баласының
дүрт саны төзек һәм
иманы булсын сау...

* * *

Җирдә җиде җәүһәр.
Тиңләре җитмәслек...
Адәм баласының,
мәңгелек боз эргәч,
ис-аклы китмәсме?..

* * *

Уеннан уймагы
чыгып кына торыр...
Адәм баласының
уеннан алдарак
шайтаны котырыр...

* * *

Дин, тел, милләтенә –
тәкәллефсезлеге...
Адәм баласын гел
чыгырдан чыгарыр
бәрәңгесезлеге...

* * *

Карап торышына
талымсызлык чыккан...
Адәм баласының
күзе барыбер дә
кызылга кызыккан.

* * *

Буе җитмәгәнгә –
«өлгермәгән җимеш».
Адәм баласының
үткен балтасына
кагылмый бу «имеш»...

* * *

Сыер су эчкәндә,
бозау боз ялаган.
Адәм баласына
бу мәкаль-әйтемнәр
инде бар да ялган...

* * *

Хөсетлек – үтмәс чир,
дәвасын кем табар...
Адәм баласының
күрше бакчасына
мең ел алтын явар.

* * *

Кендеге – әбидән.
Сөннәте – бабадан...
Адәм баласына
хәер-фатиха да
төшүгә табадан.

* * *

...Яшь тайны карт бия
кешеннәп аздырган...
Адәм баласын да
акыл теше, төшеп,
мәсхәрә калдырган...

* * *

Вакытсыз картайган –
ни кылма мантымас...
Адәм баласының
фәкать хөр күңеле
таякка калдырмас...

* * *

Ярын югалтканның
күңеле имгәнгән...
Адәм баласының
сөеп сөелгәне
бәхеткә кинәнгән.

* * *

Ал бирсә – ат елый...

Бирмәсә – ул яна...
Адәм баласының
шуңар ирешкәне
ир-ат исмен ала...

* * *

Ай – Җирнең күктәге
мәңгелек сәгате...
Адәм баласының
күк ихтыярында
холыгы-халәте...

* * *

Килере билгеле –
билгесез сәгатьтә...
Адәм баласы ни
үзгәртә ала соң,
алдан белеп хәтта?..

* * *

Йомырка, тавыкмы –
кайсысы беренче?..
Адәм баласының
фикере – берсеннән
берсенә йөреше...

* * *

Кәгазь дә саргая...
Вәгазь дә искерә...
Адәм баласына
Иблиснең өр-яңа
ялганы тиз керә...

* * *

Кояш йөрешендә
елы... фасыллары...
Адәм баласының
шуңар бәйле җирдә
яшәү асыллары...

* * *

Якынайса – янар,
ерагайса – туңар...
Адәм баласына
үз чигендә генә
яшәү фарыз шуңар...

* * *

Атканы – таңында...
Батканы – кичендә...

Адәм баласының
гомренең яртысы
шул ара эчендә...

* * *

Байларга – мамыгы...
Ярлыга – ябага...
Адәм баласының
килере-табары
тамрында ярала...

* * *

– Ал, – дигәндә алыр...
– Бир, – дигәндә бирмәс...
Адәм баласының
нәсел-нәсәбеннән
шул гадәте бизмәс...

* * *

Дымсуда – сабакка...
Корыда – тамырга...
Адәм баласына
хәтта шул билчәннән
гыйбрәтләр алырга...

* * *

Тырышкан барыбер
ташка кадак каккан...
Адәм баласының
ата ялкавы да
белә шуны яттан...

* * *

Куй, елкы көтүе...
Түбәсе, торбасы...
Адәм баласының
мең ел мең чакрымда
билгәән даласы...

* * *

Гәүдәсенә күрә
шәүлә-күләгәсе...
Адәм баласының,
шөкер, салымы юк –
шуңар түләнәсе...

* * *

Атына карап та
салына солысы...
Адәм баласының

үз урнын беләме
кечесе, олысы...

* * *

Ярлы ятагында
Ямьсез яры ятар...
Адәм баласының
бары үз әнкәсе
матурлардан матур.

* * *

Хаҗәте – йөгәнсез...
Әҗәте – дилбегә...
Адәм баласының
шуңарга тарганы
гомергә бил бөгә...

* * *

Дугасын бөккән дә
тәртәсен күтәрткән...
Адәм баласының
тәү кат ат җиккәне
язмышын үзгәрткән.

* * *

Бик тә бай юмартка
юлыгасы килә...
Адәм баласының
һәммәсе биектән
егыласы килә.

* * *

Чәчләре чаларган,
йөзен сары алган...
Адәм баласының,
җәе тиз үтсә дә,
күзе соңармаган...

* * *

Ташта сын-тамгасы...
Тузда сын-сурәте...
Адәм баласының:
– Асылың җуйма! – дип
язган васыяте...

* * *

Җиләге – тәлгәштә,
алмасы – агачта...
Адәм баласының
әле ашыйсы бар,
үрелеп алгач та...

* * *

Диңгезгә җитәре –
чишмә, инешендә...
Адәм баласының
гомерлек дигәне
тамры тибешендә...

* * *

Күк – җиде түбәле...
Җирнең – җиде каты...
Адәм баласының
җаны һәм җәсәде
шуннан урап кайтты...

* * *

Яу ау түгел, белми
кем кайчан кайтырын...
Адәм баласының
яуга киткән көннән
аулыйлар хатынын...

* * *

...Тәннең китәсе юк,
җанның каласы юк...
Адәм баласының
шуны үзгәртерлек
һичбер чарасы юк...

* * *

...Данлау, мактау – бары
шайтан имезлеге...
Адәм баласының
дулап дауламасын
өчен тигезлеген...

* * *

...Барысы буйсынган
көтү Анасы бар...
Адәм баласына
карусыз бүредән
гыйбрәт аласы бар...

* * *

...Ялган дәрәҗә, дан –
салпы якка салам...
Адәм баласына,
масаеп азсынга,
шайтан сузган хәрәм...

* * *

...Бозлык чорында да
тәнне тән җылыткан...
Адәм баласына
ана сөте белән
керерен җен йоткан...

* * *

Алашага – тышау...
Айгырга – арата.
Адәм баласының
башында бармы уй
шул хәлгә карата?

* * *

Хөрмә һәм хур кызы –
оҗмах җимешләре...
Адәм баласының
күңле шайтан коткы--
сында килеш әле...

* * *

Кешелек – чоңгылда:
бик астан менәре...
Адәм баласының
җан кыюдан ары
юк оста һөнәре...

* * *

Хәләл гомер иткән
тәмугта янмаган...
Адәм баласының
нәфсе мәңге чикмәс
тыелган алмадан.

* * *

...Хатадан хали зат
кул кушрып утырган...
Адәм баласының
басып торганы да,
йөз еглып, йөз торган.

* * *

...Туган туганыннан
йөз чөергән заман...
Адәм баласына
бәхет чит-ятлардан
явар сыман һаман...

* * *

...Таңнар атып торыр...

Кояш батып торыр...
Адәм баласының
әрәм гомеренә
күк шаккатып торыр...

* * *

...Сөю – канның, җанның
шашып котыруы...
Адәм баласының
шул татлы газаптан
юктыр котылуы...

* * *

Нәфесен тыялган –
күңеле камил зат.
Адәм баласына
гап-гади хакыйкать
нилектән шулай ят?

* * *

Һәркемнән шикләнгән –
үзенә бикләнгән...
Адәм баласының
килере-табары
учында чикләнгән...

* * *

«Дөнья куласасы
әйләнеп басасы...»
Адәм баласына
әллә шуны язып
муйнына асасы?!

* * *

Тугры юл – савапка,
кыек юл – газапка...
Адәм баласының
кыйбласызлыгы
газаплы азакка...

* * *

Дошманлык – шайтанның
җәтмәсен корышы...
Адәм баласының
бер-берсен каргашып,
орышып торышы...

* * *

Хиссез мәгънә – таштыр,
уйны уй буташтыр...

Адәм баласының
шигырьле мизгеле
күкләргә тоташтыр...

* * *

Кошлар ел да кайтып
кора үз оясын...
Адәм баласына,
оятын уятып,
куышын корасы!..

* * *

Урман, дала, кырда
кыргый эт көтүе...
Адәм баласының
көтеп йөриме алар
мур кырып бетүен?

* * *

Туган туфрагыннан
көчләп кубарылган
Адәм баласының
юк кайтыр Ватаны,
аты тугарылган.

* * *

Хәер акчасын да
алыр иде көрәп...
Адәм баласының
чүпле бакчасында
сынык саплы көрәк...

* * *

...Нәфесе чигенгән
һәр адым җаваплы...
Адәм баласының
чамасы чигеннән
чыкмавы саваплы...

* * *

Вөҗдан мыскалында
явызлык, игелек...
Адәм баласының
уе – корсагында:
шул әле иң элек...

* * *

Эт – дус, бүре – дошман.
Һич юк бутыйсы...
Адәм баласының

теккән эт тиресе
бүреге, унтысы...

* * *

Козгын тавышында
фаразның шомлысы...
Адәм баласының
җирдә шүрләп үтә
бер карыш тормышы.

* * *

Хәерче илнең дә
үзенчә бае бар...
Адәм баласының
бер-берсе әҗерен
чәлергә җае бар.

* * *

Көтеп килмәс бәхет,
көтми килер кайгы...
Адәм баласының
үтәрме бер көне
шул хәленнән айры?

* * *

Арты – каз мендәрдә,
телендә – бал да май...
Адәм баласының
картайган көннәрдә
чалма, чапаны җай!..

* * *

Көләргә теләсәң,
бетәрме хөрәсән?..
Адәм баласының
һәрберсе – эч катып
көләрлек бер әсәр...

* * *

Кызыл шигырь язып
дан-шөһрәт казанган
Адәм баласының
иҗатын җирлиләр
үзеннән алдарак...

* * *

Ай тотылган төндә
күңелне шом баса...
Адәм баласының
бердәнбер тугыры
юлдашы шул ласа...

* * *

Гел корбаннан тора
җирдәге тормышы...
Адәм баласының
чарасызлыгымы
тормышын кормышы?..

* * *

Ике дөньяда да
мал, дан бүлеше бар...
Адәм баласының
савабынча табар
алтын-көмеше бар...

* * *

Байлык – бер айлыктыр,
ярлылык – гомерлек...
Адәм баласына
бетмәс байлык – иман,
оҗмахка керерлек!

* * *

Тиранны астылар –
хөкемдарга хөкем...
Адәм баласына
юкса күпме гасыр
кисәтелде бу көн!..

* * *

Язып асыйкмы дип
«мирас орлыгыннан»...
Адәм баласына
котылу насыйпмы
нәфсе коллыгыннан?..

* * *

Үзендә булмаса,
ничек тә ул түзәр...
Адәм баласының
көндәше мал тапса,
эчтән телеп өзәр...

* * *

Мыскалга салынган
дөнья малы, гаме...
Адәм баласына
шайтан сузып тора
тыелган тәгамне...

* * *

Ярда яткан балык –
нибары үләксә...
Адәм баласының
хәле шул балыктай,
чит ярга эләксә...

* * *

Гап-гади тәгәрмәч
киткәнче тәгәрәп...
Адәм баласына
мәгарәдән чыгу
бойрылды элгәрәк...

* * *

Басынкы бу инеш
язларда ярсулы...
Адәм баласының
гомере шуңа иш:
ярлы һәм ташулы...

* * *

Соңгы барыш – зират,
соңгы кичү – сират...
Адәм балалары
сабыр итеп баскан
иң беренче чират.

* * *

Кылган бар гамәле
эшендә, ашында...
Адәм баласының
иң соңгы хәбәре
кабере ташында...

* * *

Иҗат – Илаһыдан:
җан – ихтыярына...
Адәм баласына
яшәү ихтыяҗын
һәрчак тоярына...

* * *

Йозак бикләр өчен,
Ачкыч – ачарына...
Адәм баласына
инандыр шуларны
онытачагына...

* * *

Җиткәннәрме барып...

Калганнармы туктап...
Адәм балалары
көтү-көтү йөри,
үлән-яфрак утлап...

* * *

Түләнмәгән бурыч,
үтәлмәгән вәгъдә...
Адәм баласында
гомер бетәсе юк
бер-берсенә дәгъва.

* * *

Юраган юш килә,
ни килсә – буш килә...
Адәм баласына,
телен тешли-тешли,
кыйммәтле һуш* килә.

* * *

Сылу – сокланырга,
түгел табынырга...
Адәм баласына
тигез юлда күпме
мөмкин абынырга?..

* * *

Баш игән бил бөгәр,
Бил бөккән тез чүгәр...
Адәм баласының
баш имәгәненнән
тез чүккән йөз чөяр.

* * *

Яктылык елының
үзгә фасыллары...
Адәм баласының
нурга әверелеп
күрер кайсылары?..

* * *

Йөргән таш шомара,
йөргән акча туза...
Адәм баласының
гомере таш актарып,
акча диеп уза...

* * *

...Ташпулат – курасы,
туп-тулы бурасы...

Адәм баласының
һаман саен киләбердәнбер буласы...

* * *

Тимердән су сыгар,
судан кысар тимер.
Адәм баласының
хыял-ихтыяры
омтылган көн килер.

* * *

Дан һәм Вөҗдан мәңге
дучар сыналуга...
Адәм баласына
төшендерү бик тә
зарур сын алуга...

* * *

...Сокландыра кайсы,
кызгандыра кайсы...
Адәм баласының,
баксаң, нәкъ шул хәлгә
омтыла һәркайсы...

* * *

Капкан саен калҗа,
йоткан саен шәраб...
Адәм баласының
тамак ялы өчен
эшенә ишарә...

* * *

Җырында хәтере
җуелмас уелган
Адәм баласының
дөньяга әйтере –
«Карурман», «Уел»дан...

* * *

Җир-Ана! Хак бәя,
тирәнтен уйласаң...
Адәм баласында
җирсү – иң самим хис,
хәтерен җуймаса...

* * *

Салават күпере –
күкләрнең әләме...
Адәм баласына

чистарынган саен
җибәргән сәламе...

* * *

Уй җитмәс ерактан,
буй җитмәс арадан
Адәм баласына
аеру фарыздыр
акны дөм карадан...

* * *

Булганда – бүредәй...
булмаса – шүредәй...
Адәм баласының
ачлык кичергәне
үз хәлен белердәй...

* * *

Баш исә – басарлар...
Имәсә – асарлар...
Адәм баласының
урталыктагысын
шәп түрә ясарлар...

* * *

Су, балчыкта һәрчак
тереклек ярала...
Адәм баласының
бер тамчыда хәле
мәңгегә барала...

* * *

Үз санын, үз сынын
саклаган сакланган...
Адәм баласының
тагын мең гасырга
үтәре акланган...

* * *

Авызда кара кан,
ашында таракан...
Адәм баласын Хак:
– Төкерә күрмә, – дип,
кисәтеп яраткан...

* * *

Түбәтәе җәлпәк,
шулай да чигелгән...
Адәм баласының
башы ни кияре
тәкъдирдә диелгән.

* * *

Башын бәргән ташка –
уалып беткән таш...
Адәм баласының
таш ватар башында
авыз, борын, күз, каш...

* * *

Дөньясында ни бар –
исәбе санында...
Адәм баласының
ун бармагы җитә
шулар хисабында...

* * *

Кояшны каплады
көннең уртасында...
Адәм баласына
тулган ай, кисәтеп,
нидер әйтте сыман...

* * *

Барган-килгәнендә,
алган-биргәнендә...
Адәм баласының
бөтен чагылышы
тәкъдир дигәнендә...

* * *

Бөек яралышның
даһи иҗатчысы
Адәм баласының
ҖИРенә төшергән
беренче яктысын...

* * *

Котып бозы эреп,
җирне туфан басар...
Адәм баласының
кем атлысы тагын
нинди көймә ясар?..

* * *

Хыял гына түгел,
чынбарлыгы шулай...
Адәм баласының
күккә ашкынуын
ҖАНы, РУХы сорай...

* * *

Кап-кара төннең дә
бар сүрелмәс нуры...
Адәм баласының
күңеле күгендә
өметенең зуры.

* * *

Сүз – галәм илчесе,
әйтә, тыңлый белсә...
Адәм баласын ул
мәңгелеккә илтер,
мәгънәсенә керсә...

* * *

Күтәргән кылычын
ормыйча төшерде...
Адәм баласы үз
әҗәле сәгатен
йөз адым күчерде...

* * *

Эзенә төшалган
эзләгәнен табар.
Адәм баласының
өзелгән эшенә
эремәс кар явар.

* * *

Шөкер иткәнендә
бәхете ишелер.
Адәм баласының
тәкәбберлегендә
килере киселер...

* * *

Дәшми кадалганның
хакы сары алтын...
Адәм баласын шул
кыйммәт әдәплеге
йөз елга соңартыр...

* * *

Ачның күзләрендә,
тукның корсагында...
Адәм баласының
«Җитте» диячәге,
күзе туйса гына...

* * *

Изгегә тартамы

вәгазе, каләме...
Адәм баласының
йокмаган сүзенә
ятышмы гамәле?

* * *

Язын чәчсә, көзен
тулы көшеле дә...
Адәм баласына
шушы хакыйкатьне
фарыз төшенергә...

* * *

Шәрәлек – ишарә
ач, ярлылыгына...
Адәм баласының
ишарәсе нидә
тук азгынлыгына?

* * *

Барысы да үтә,
бөтенесе кала...
Адәм баласының
гомер дәрьясында
тәкъдире чайкала...

* * *

Җәяү киткәне бар,
атын җиккәне бар...
Адәм баласының
җитү ниятеннән
артка чиккәне бар...

* * *

Хөсетлек – хасталык,
име имгә иңмәс...
Адәм баласының,
күңлен госелләми,
зәхмәте чигенмәс...

* * *

Белеп торганы бар,
көлеп торганы бар...
Адәм баласының
кул-аягы озын,
тик ябынганы тар...

* * *

Тамчы да матдәнең
мәңгелек бер мәле...

Адәм баласының
хәтерендәме шул
хәлендәге хәле?..

* * *

Мактап үтерәләр,
үтереп мактыйлар.
Адәм баласының,
«җидесе» үтүгә,
каберен тапмыйлар...

* * *

Тойгы йогынтысы
якынлыкка илтә...
Адәм баласының
талымсыз хисләре –
акылына киртә...

* * *

Мең ел элек ташка
сугылган сурәте
Адәм баласына
мәгънәсез бер шөгыль
булуын күрсәтте...

* * *

Яратып яралган
Хак ризалыгында...
Адәм баласының
барып җитәр җире
ерак узганында...

* * *

Сан хисабындагын
килмәс югалтасы...
Адәм баласының
утырган ботагын
чабар үз балтасы...

* * *

Юраган юш килде –
кыя тау ишелде...
Адәм баласының
тәүбәсе, басылып,
урталай киселде...

* * *

Мәгънәсен эзләп тә
төшенми китеше...
Адәм баласы – бу

бөек яралышның
сайланыш җимеше...

* * *

Хиссез сүз, иссез гөл...
Тәэсире сүрән...
Адәм баласының
күңеле бакчасын
сарыган чүп үлән...

* * *

Күргәненнән качар...
Күрәчәген ачар...
Адәм баласының
басып торган җире
нигәдер гел начар?..

* * *

Сабыры төбеннән
табылыр алтыны...
Адәм баласының,
ялтыраган саен,
бәгыре катармы?..

* * *

Күренеп торганын
тотып карап була...
Адәм баласының
кулын күп сузганы
күбрәк харап була...

* * *

Күтәрелгән саен,
офыгы киңәя...
Адәм баласының
күңеле киңлегенә
түбәндә хак бәя...

* * *

Чигенә җиткәндә,
чигенүе кыйммәт...
Адәм баласының,
кирәге беткәндә,
тибелүе гыйбрәт...

* * *

Олпатлык – акыл да,
отып ала белсә,
Адәм баласын ул
күкләргә күтәрер,
тотып кала белсә...

* * *

Ләхете өстендә
тар, түбән түбәсе...
Адәм баласының
бөтенесенең дә
бар шунда керәсе...

* * *

Көннең яктысы бар,
төннең карасы бар...
Адәм баласының
шулар арасында
яшәп каласы бар...

* * *

Бер бөгелде исә,
ап-ачык сынасы...
Адәм баласының
бөгелмәскә итә
үҗәт юккынасы...

* * *

Җирнең чите чиксез,
күкнең чите чиксез...
Адәм баласының
чикле гомерендә
күпмесе билгесез?!

* * *

Фиргавен токымы
йөз гасыр көн иткән...
Адәм баласына,
сабакланыр өчен,
шулар да аз икән?

* * *

Галәмнәр үлчәме
санга салынгандыр...
Адәм баласына
ачылыр бар сере
ун бармагындадыр...

* * *

Исә җил, кисә җил,
чүл күчә, күл кибә...
Адәм баласына,
кылмасын ни генә,
кисәткән көн килә...

* * *

Сарысы төштисә,
озак тартмас дигән...
Адәм баласының
тәкъдирендәгесе
бер тын артмас дигән...

* * *

Чүлнең – үз чәчәге,
Сазның – үз җиләге...
Адәм баласына
ничек тә бер чыгар
шуларның кирәге...

* * *

Тарафы билгеле,
җаны җитәре бер...
Адәм баласының
рухы биеклеге
кадәр күтәрелер...

* * *

Бер баскыч менүгә,
икенчесе баса...
Адәм баласының
үтәчәк юлында
мәңгелек куласа...

* * *

Куаныч күтәрер,
Хәсрәт төпкә тартыр...
Адәм баласының
кайчан, кайда, ничек
шул халәте артыр?..

* * *

Тәне – су, сөяктән,
Тиресе каплаган...
Адәм баласының
тәкъдирендәгечә
җан тәнен саклаган...

* * *

Күзен йомып үтә
гомренең яртысы...
Адәм баласына
тигез хаҗәттәме
караңгы, яктысы?..

* * *

Төсе хәбәрендә

җисме үзгәлеге...
Адәм баласының
күзе алмасында
үзгә гүзәллеге...

* * *

Киек Каз Юлында
тынгысыз мәңгелек...
Адәм баласының
зәгыйфь иманында
мәҗүси тәңрелек...

* * *

Кояшны ничә кат
Ай каплап караган...
Адәм баласына
күкләрдән ап-ачык
сабак дип каралган...

* * *

Итәген кисәр дә
Җиңен ямап куяр...
Адәм баласының
шул һөнәрен хәтта
кемдер мактап куяр...

* * *

Көмеш эреткәне,
Алтын йөгерткәне...
Адәм баласының
затлымы һәрберсе –
тәне йөреткәне?..

* * *

Мәңгелек юлдашы
Атыннан бизенгән...
Адәм баласының
нәсел-нәсәбендә
хәлсезлек сизелгән...

* * *

Аң дәрәҗәсенә
күтәреләм дигән
Адәм баласы иң
әүвәле бердәнбер
булудан бизенгән...

* * *

Күбәләк күреп тә,
бәйдәге эт өрә...

Адәм баласының
коллыкка күнеккән
төренә бер кинә...

* * *

Алма агачыннан
ерак төшмәсә дә...
Адәм баласының
иле-бакчасында
бу бер чүп мәсьәлә...

* * *

Сөзелеп алганы,
Сайланып салганы...
Адәм баласының
талымсыз, карусыз--
ларына калганы...

* * *

Яндырып өшетер
газап, әрнүләре...
Адәм баласының
үз башына төшәр
нахак рәнҗүләре...

* * *

Тамчы тамып тора,
ташны ярып тора...
Адәм баласының
күреп күрмәгәне
башын кашып тора...

* * *

Күккә терәп корган
пирамидалары –
Адәм баласының
җил хөкемендәге
каберлеге бары...

* * *

Дөнья тотканына
хәйран каласың да...
Адәм баласының
йорты-малы һаман
арба-даласында...

* * *

Миң чакрым таш дивар –
кемнән кем сакланган?..
Адәм баласының

бу чарасызлыгы
мең елдан акланган...

* * *

Сорап йөргәне бар,
йөреп тапканы бар...
Адәм баласының
сорап йөрмичә дә
корган капканы бар...

* * *

Өс бөтен, тамак тук,
малы утарында...
Адәм баласына
бернинди сәбәп юк
«ары» буталырга...

* * *

Мәктәбе, мәзһәбе...
Йоласы, кыйбласы...
Адәм баласына
туа-тумышыннан
шуңар сыенасы...

* * *

Дүрт ягына карап
гыйбрәт ала белгән
Адәм баласының
имәненә тәкъдир
чикләвеген элгән...

* * *

Чигенмәс бер чире,
үтмәс үкенече...
Адәм баласының
тәүбә итми торып
бетмәс үтенече...

* * *

Күлдәге бер тамчы,
күктәге бер болыт...
Адәм баласының
бердәнберлеген кем
саклап калыр йолып?..

* * *

Кайчан килеп кайда
алып китсәләр дә,
Адәм баласының
ике фәрештәсе
калыр иңсәләрдә...

* * *

Ялган да ялгана,
Яла да ягыла...
Адәм баласының
нәсел-ыруына
ярлыгы тагыла...

* * *

Җан исәп алганда,
теленнән язмаган
Адәм баласын үз
нәсел-нәсәбеннән
беркем сызалмаган.

* * *

Хисе – ниятендә,
хаҗәте – көчендә.
Адәм баласының
диңгез кичкәне бар,
бер күрер өчен дә...

* * *

Яктырып атадыр,
сүрелеп батадыр...
Адәм баласының
шуңар табынуы –
гөнаһсыз хатадыр...

* * *

Коткарса коткарыр
тик тәүбәсе генә...
Адәм баласының
гөнаһсыздыр, бәлки,
тик шәүләсе генә...

* * *

Янәшәсендә кем?
Анык белсә генә,
Адәм баласының
сузылып тешлисе
юк үз терсәгеннән...

* * *

Бер калак – бер өлеш,
бер табак – ун өлеш...
Адәм баласының
табагындагысын
калагымча бүлеш...

* * *

Эсседә әлсерәп,
суыкта сулыккан
Адәм баласының
һәркайсы тәкъдире
юлына юлыккан...

* * *

Болытка баш төрткән
пирамидалары...
Адәм баласының
кавеме башкорттан
дип расланыр әле...

* * *

Сынау газаплары
үлгәч тә үтмәстер...
Адәм баласының
сынукка сылтавы
анда да бетмәстер...

* * *

Милләтең, телең ни –
уе йорт-курада...
Адәм баласының,
шөкер, бәрәңгесе
туп-тулы бурада...

* * *

Кодрәте көчендә
күк тора эленеп...
Адәм баласының
аласы бирелер,
каласы беленеп...

* * *

Җан чыгып китәр дә,
суынып калыр тән...
Адәм баласына
кыямәт көнгәчә
инде кайтмас бүтән...

* * *

Арасы якын да,
юллары ерактыр...
Адәм баласының
монда туфрак, анда
көл буласы хактыр...

* * *

Тамырына төште

аяусыз корылык...
Адәм баласының
күләгәдәгесе:
«Шөкер», – дип торырлык...

* * *

Шайтан – бер, җен – башка,
бүген ни күргәне:
Адәм баласының
шайтаны котырып,
җенләнеп йөргәне...

* * *

Бер тыңлап торып та,
ап-анык белерсез...
Адәм баласының
салымы – алымсыз,
алымы – керемсез...

* * *

Корылык җәһәннәм
җиленнән яралган...
Адәм баласына,
күнегә торсын дип,
күрәсең, каралган...

* * *

Тәкъдир биләмәсен
вакыт киртәләгән...
Адәм баласының
кайсы соңарган, йә
кайсы иртәләгән...

* * *

Уттан һич калмады,
бурдан калыр иде...
Адәм баласының
тугры ун бармагы
умрып алыр иде...

* * *

Барып җитәренә
кул сузымы бары...
Адәм баласының
туктап калганы бар,
үз-үзеннән арып...

* * *

Теле-телгә йокмас,
кулы-кулга йокмас...

Адәм баласының
чәйнәгән чүбенә
чебен дә йолыкмас...

* * *

Көлеп кинәнгәне,
Көлкегә калганы...
Адәм баласының
һәр ике халәтен
өлгертә ялганы.

* * *

Кем йогынтысына
юлыгып торыр гел?..
Адәм баласының
нахак яласына
сулыгып корыр гөл...

* * *

Язмыш дәрьясының
калыр кай ярында?..
Адәм баласының
туфрак булыр төше
күк ихтыярында...

* * *

Камиллеккә өлге –
самим гадилеге...
Адәм баласының
ана сөте белән
сугарылган гөле...

* * *

Галәмнәрнең үзгә
елы фасылында
Адәм баласының
үзгәреп торадыр
каны басымы да...

* * *

Бөек Рух мәңгелек
чиксез ералышта...
Адәм баласының
тәнендәге җаны
шуңар бәгланышта...

* * *

Җирнең бөтен сере
су төбендә калган...
Адәм баласының

Коръәнле кавеме
ачар шуны алдан...

* * *

Кан белән языла,
сан белән саклана...
Адәм баласының
ак таплы тарихы
тәкъдир дип аклана...

* * *

Сораганда – баллы,
биргәндә – борычлы.
Адәм баласының
дөньясында барсы
тик аңар бурычлы...

* * *

Бүрәнә аркылы
бүре куганы бар...
Адәм баласының
бүрене буардай
тугры туганы бар...

* * *

Сабагына төшсә,
тамырына күчәр...
Адәм баласының
канын бутаганы
ахырына дучар...

* * *

Барып кайтышында,
алыш-бирешендә...
Адәм баласының
холыгы-фигыле
табыш-килешендә...

* * *

Тукран тәүбәсенең
савабы үзенә...
Адәм баласының
соңарган тәүбәсе
соңарган көзенә...

* * *

Тартайның тапканы
тиктормас теленнән.
Адәм баласына,
тик телен тешләгәч,
шул хәбәр беленгән.

* * *

Бөтәеп бүленү –
тереклек кануны...
Адәм баласының
хыялый нияте –
бүленми калуы...

* * *

Төлкенең койрыгы
әҗәленә илтә...
Адәм баласының
алтын җыйганы да
җәһәтерәк китә...

* * *

Үзенә килмәсә,
торынына килер...
Адәм баласының
гариптән көлгәне
тилмереп тилерер...

* * *

Кояшы байганда,
кем кемгә юлыгыр...
Адәм баласының
кайсысы кайларда
мәңгегә күз йомыр?

* * *

Гомерне ничек тә
була ул уздырып...
Адәм баласының
бар ыру нигезен
атканы туздырып...

* * *

Кайчан да булса бер
кызыл кар явачак...
Адәм баласының
барсы, тәүбә итеп,
сәҗдәгә авачак...

* * *

Сәламен биргәндә,
алганда сәламен,
Адәм баласының
тәгаен беленә
гаиләсе әдәбе...

* * *

Ялгыз ятагына
төште ай яктысы...
Адәм баласының
чыклы керфегендә
мәхрүмлек чаткысы.

* * *

Мантыйкка сыймаслык
кардәшләр орышы...
Адәм баласының
Иблис кыйбласында
бер-берсен кырышы...

* * *

Йөреп тормадисә,
юлын үлән баса...
Адәм баласының
килер-китәр юлы
күкләрдә ләбаса?..

* * *

Галәмнәр эчендә
галәмнәр бар иткән...
Адәм баласының
җанын бер, тәннәрен
кушарга пар иткән...

* * *

«Бар бул!» – дигән Бер Хак
җаны яралсынга...
Адәм баласына
кодрәти хис биргән
үрчеп таралсынга...

* * *

Тиңдәше юк ләззәт
хисе чормасында...
Адәм баласының
сөю-сәгадәте
ике дөньясында...

* * *

Тулып пешкән җиләк –
татлының татлысы...
Адәм баласының
гыйффәтле сафлысы –
ахирәт затлысы...

* * *

Гыйшык касәсенең

мөлдерәмә чагы –
Адәм баласының
тамчылап тулганы –
керфеге очлары...

* * *

Янды йөрәк, янды,
дөрләп ялкынланды...
Адәм баласының
шашкын хисләренә
йолдызлар таң калды...

* * *

Хурларын, хөрмәсен
Күрәсе киләдер...
Адәм баласының
тыйганнан тыйласы
килми тик нигәдер...

* * *

Азгынлык азагы –
төпсез караңгылык...
Адәм баласының
рухы тазалыгы
(о)зата баралырлык...

* * *

Ир бирмәк – җан бирмәк,
кем кайчан күргәндер?..
Адәм баласының
ничә меңнән бере
иренә бирдәнбер?..

* * *

Күзе кызганы бар,
түзеп торганы бар...
Адәм баласының
хәрәм хозурлыкка
үзгә корбаны бар...

* * *

Яшәеше – уен,
бихисап төрләре...
Адәм баласының
уены барында,
ил-көне төрмәле...

* * *

Хәрәмен күз йомып
күрмиләр дисәк тә...

Адәм баласының
оныгына төшәр
газабы исәптә...

* * *

Коега төкергән--
нең теле кибеккән...
Адәм баласының
кысыр калуының
сәбәбе нилектән?..

* * *

Хыялый мәхәббәт,
йә, кайларга илтмәс?
Адәм баласының
серле шул хисләрен
язарга сүз җитмәс...

* * *

Сүзен уйнатса да
сөйләмәс уен сүз...
Адәм баласының
тартканы – керфек тә,
төрткәне – ике күз...

* * *

Авырын алмаска
алымы остара...
Адәм баласының,
«ашыгып» барса да,
адымы кыскара...

* * *

Йөрдисә – таба да,
чамасы чамада:
Адәм баласының
җәйгесе – арбада,
кышкысы – чанада...

* * *

Челләдә чүл гизә,
кырлачта котыпта...
Адәм баласының
үҗәт ниятеннән
булмый котылып та...

* * *

Күп сөйләгән теле
ни зыян итмәгән...
Адәм баласының

телчәнен карга да
күтәреп китмәгән...

* * *

Һаман шул тырмага
китерә дә баса...
Адәм баласының
маңгае чуеннан
түгелдер ләбаса...

* * *

«Үтеп китте», – дисең,
тагын килеп баса...
Адәм баласының
эзәрлекләгәне
ачыгу лабаса...

* * *

Гадәте калыр шул,
хәтта чире китәр...
Адәм баласының
«иртәгә» дигәне
гомеренә җитәр...

* * *

Югалган табылыр,
янганы – көл генә...
Адәм баласының
гомере югалган,
янганмы – кем белә?..

* * *

Агач башын борды
кубарып искән җил...
Адәм баласының
кыйбласы үзгәрде,
талап бүленгәч ил...

* * *

Ил нидән башлана:
кавем, ыруданмы?
Адәм баласының,
әхлагын канунлап,
гаилә коруданмы?..

* * *

Гаепле сәбәпче
һәрчакта табылыр...
Адәм баласының
Ярлысына яла
күбрәк ягылыр...

* * *

Кигәне затлыдан,
Капканы татлыдан...
Адәм баласының
җыелган бурычы
юмарт беркатлыдан...

* * *

Илчегә үлем юк,
тылмачка тыем юк...
Адәм баласының
кәсебе җаенча
үткәрмәс кыен юк...

* * *

Сабыйда – самимлек,
акыл – аксакалда...
Адәм баласының
сакаллы сабыен
йә кем дип атарга?..

* * *

Милләте хәстәрен
күреп торганы бар...
Адәм баласының,
милләт дип такылдап,
теле корганы бар...

* * *

Авырткан башына
таш орды замана...
Адәм баласының
башы таш ярганы
ташбаш дип санала.

* * *

Әңгер-меңгерендә
тәмам сукырая...
Адәм баласының
җитәкләп баруы
кемне, кайсы, кая?..

* * *

Сыеклап саталар –
ана сөте юкса...
Адәм баласының
әдәп, әхлагына
нәфесе бер сукса...

* * *

Язын алганын да
күзен саныйсы бар...
Адәм баласының
ялган хисабында
үзен таныйсы бар...

* * *

«Торып тор» дигәне
алдан бармак була...
Адәм баласының
кәкре ун бармагы
көрәп алмак була...

* * *

Байдан сорамаган,
ярлыга бирмәгән...
Адәм баласының
кысып тотканының
уч төбе тирләгән...

* * *

Үтмәс үләт чире
җанына тигәч тә...
Адәм баласының
китәсе килмәстер,
элмәген кигәч тә...

* * *

Биргәнен алыры –
аның ихтыяры...
Адәм баласының
шуннан качып калу –
мәңгелек хыялы...

* * *

Тормышта үз җаен
тапканчы эзләгән.
Адәм баласының
ният-теләгенең
әҗерен өзмәгән...

* * *

Дусты бар, дошманы,
чыны бар, ялганы...
Адәм баласының
ашы таракансыз
бар микән калганы?..

* * *

Капкан саен калҗа,

чапкан саен түшкә...
Адәм баласының
булдыралганына
бу эш тормый чүпкә.

* * *

Насыйп мал, насыйп яр,
таш кыя, упкыны...
Адәм баласының
кайсын кая илтер
язмышы дулкыны?..

* * *

Ел да корбан чалып
савап җыя торды...
Адәм баласының
тәүбәсез тәгаме
ыруына орды...

* * *

Бөтенесен җыеп,
үзенеке иткән...
Адәм баласының
көтмәгәндә генә
тынычлыгы киткән...

* * *

Буе җитмәгәнгә
үрелсә дә тимәс...
Адәм баласының
һич булдыксыз булып
күренәсе килмәс...

* * *

Котылырмын димә,
ярлыгы тагылса...
Адәм баласының
имансызлыгына
аклану табылса...

* * *

Кысыр хәсрәте дә
һаман үрчи генә...
Адәм баласының
үзен сөймәгәне
яраттыра белә...

* * *

Эзләп-эзләп тә күп
таптыралмаганы...

Адәм баласының
бармы: «Нидән бу?» – дип
аптырамаганы?..

* * *

Үз бәһасен белеп
түбәнсеттермәгән...
Адәм баласының
ил-көненә Иблис
этен өстермәгән...

* * *

Нияте, куәте
уе-теләгендә...
Адәм баласының
тереклек итәре
иле терәгендә...

* * *

Фәрештә – уң囂 эштә
хуплап торучысы...
Адәм баласының
бисмилласызының
шайтан – йотучысы...

* * *

Хагын нахагыннан
Аралар иде дә...
Адәм баласының
дуамал илендә
хөкем юк тилегә...

* * *

Соңгы чиктә чаян
үзен үзе чага...
Адәм баласына
котылгысызлыктан
сәрхушлыгы чара...

* * *

«Төшеп җитәм!» – дияр
төбен эзләгәне...
Адәм баласының
ниятеннән бизмәс
өмет өзмәгәне...

* * *

Хуплап торганы бар,
арка борганы бар...
Адәм баласының

якыннан якыны
ерак торганы бар...

* * *

Арыслан булсын да
тычкан тотсын, имеш...
Адәм баласының
чарасызлыгы да
ваклатмаска тиеш...

* * *

Шәт, уянды бөре
кыш сынган бу көндә...
Адәм баласының
йорт бүрәнәсе дә
шартламас бу төндә...

* * *

Җеназасы янып,
көлен җил таратты...
Адәм баласының
мәҗүси иманы
җанын зар елатты...

* * *

Акланам дигәндә,
сәбәбе бихисап...
Адәм баласының
бәгърenә тигәндә,
барысы ни хисап?!

* * *

Кулдан-кулга күчкән
затсызлана бары...
Адәм баласының
шуңа тарганының
мәңгелек аһ-зары...

* * *

Сүтәсе төене
чуалган, кысулы...
Адәм баласының
уйланган нияте –
хәл итү ысулы...

* * *

Кем кора-күтәрә...
Кем сүтә-җимерә...
Адәм баласының
күкрәге эчендә
теләге тибенә...

* * *

Язын ташуында...
Җәен җиләгендә...
Адәм баласының
күзе, кышы үтәр
Хәтер дигәнендә...

* * *

Бердәнбер калып та,
кадере булмаса...
Адәм баласының
йөзен – күз, күңелен
сагышлы моң баса...

* * *

Күз ачып йомганчы
югалыр ни бары...
Адәм баласының
кыямәт көнендә
коткарыр иманы...

* * *

Йөреп торганы бар,
торып торганы бар...
Адәм баласының
разый, ихтыярый
хәләл корбаны бар...

* * *

Артык йә ким түгел,
төгәл ун санында...
Адәм баласы үз
бәрәкәтен күрер,
ярдан уңса гына...

* * *

Таш сыннар, асылда,
тираннардан калган...
Адәм баласының
триумфлы тарихы
баштанаяк ялган...

* * *

Төче сүз – кечелек,
җанга үтә кереп...
Адәм баласының
үтә төчелеге
ялган дару кебек...

* * *

Терсәген тешләп тә
үтмәс үкенече...
Адәм баласының
Раббысына мәңге
бетмәс үтенече...

* * *

Чыптасы – ябага,
арканы – кылыннан...
Адәм баласының
япканы, тартканы
атында кылынган...

* * *

Белеп белмәгәндә,
күреп күрмәгәндә...
Адәм баласының
күршеләре кермәс
салкын төрмәләргә.

* * *

Йөз елдан беленер
йөзенең чын төсе...
Адәм баласының
көлкегә калдырыр
кәкере көзгесе...

* * *

Сорар өчен дә кул,
бирер өчен дә кул...
Адәм баласының,
алып бирмәгәндә,
җиңе эчендә кул...

* * *

Миләше дә ачы,
баланы да ачы...
Адәм баласының
баласы хәсрәте
ачыдан да ачы...

* * *

Яшен уты булып,
гамәлгә күчә хис...
Адәм баласының
күкләргә кирәге –
хисләре генә ич...

* * *

Тыйганына ярап

тыела белгәндә...
Адәм баласының
басканы – мөнбәрдә,
ятканы – мендәрдә...

* * *

Галәмнең үрнәге
яратылышында...
Адәм баласының
шуңар төшенгәне
күкләргә ашкына...

* * *

Галәмнәр серенә
төшенгәнче тәмам...
Адәм баласының
җирдә тереклеге
ителәчәк дәвам...

* * *

Тиңсез шартлаудан соң,
чәчелеп җыелган...
Адәм баласына
галәмнәр серенә
чыгары тыелган...

* * *

Ярымат гәүдәсе
сынын уйган ташка.
Адәм баласының
яралышыннан ук
ат биргән юлдашка...

* * *

Котыпта җил-давыл
мәҗүси ирektә...
Адәм баласының
шайтаны бизенмәс,
котыпка килеп тә.

* * *

Капкадан керүгә –
милек-ихатасы.
Адәм баласының
уртак утраклыгы –
мәңгелек хатасы.

* * *

Шаһитлар бетүгә,
шәһитләр онтыла.

Адәм баласының
зәгыйфь хәтеренә
шайтани өн тула.

* * *

Вәгазе хәдистән,
әҗере савапта
адәм баласының
гозерен хәл иткән
соравы – җавап та.

* * *

Җирсүе – тамырдан,
сусавы – сагнудан.
Адәм баласының
җирсез, илсезенә
усаллык салынган.

* * *

Байның – тыкрыгы,
Ярлының – урамы.
Адәм баласының
орлыгына карап
чәчкәне-урганы.

* * *

Ачыгып торганы,
качырып органы.
Адәм баласының
аягын сузарга
соралмый юрганы.

* * *

Телсезгә ишарә,
сукырга шар-таяк.
Адәм баласының
милли зәгыйфьлеген
беркем тормый аяп...

* * *

Тимәсә тияккә,
тияре сөяккә...
Адәм баласының
сынып бөгелгәне
торалмас сөяп тә.

* * *

Үз-үзенә читтән
карый белсә генә,
Адәм баласының

үрелеп тешлисе
булмас терсәгеннән.

* * *

Хөкемдар да үзе,
яклаучы да үзе.
Адәм баласын, үз
хәленә төшереп,
ваклаучы да үзе.

* * *

Кырыкмаса-кырык
ямау салганында –
Адәм баласының
кырыс чынбарлыгы,
шома ялганы да.

* * *

Барып җитәренә
кул сузымы ара...
Адәм баласының
арык иңнәрендә
саркып тора яра...

* * *

Таң белән уянып,
сәҗдәгә оеган
Адәм баласының
җаны Илаһысы
нурында коенган...

* * *

Келәмле өендә
келәсез ишеге...
Адәм баласының
ирекле илендә
ирексез ише гел...

* * *

Турыдан әйткәне
булмадисә туры,
Адәм баласының
җиде буынына
барып җитәр хуры.

* * *

Аю да, бүре дә,
маймыл да тамгасы...
Адәм баласының
дуамаллыгында
мәҗүси алласы...

* * *

Керфеге очында
бер тамчы энҗесе
Адәм баласын
күз тидерүләреннән
сакласын өчендер.

* * *

Оялчан йөзеннән
бөркелә сафлыгы.
Адәм баласының
заты камиллеге –
күркәм инсафлыгы.

* * *

Ярәшеп барылган,
ярәшеп алынган...
Адәм баласының
нәсел-ыруында
ярашып калынган.

* * *

Җаяүлегә офык
адым саен чиккән.
Адәм баласының
ияргә менгәне
көнен барып җиткән.

* * *

Кырлач аязында
чалт челлә күренә...
Адәм баласының
барып кайтыр юлы
икегә бүленә.

* * *

Кемнең оясына
күке күкәй салмас,
Адәм баласы, үз
кушын корса гына,
үрчемичә калмас.

* * *

Күке хәбәренә
төшендисә әгәр,
Адәм баласының
үксез ятимнәре
булмас иде мәгәр.

* * *

Зурлау, хурлау нигә
нигезсез, сәбәпсез?
Адәм баласының
сүтә белмәгәне
төзергә сәләтсез.

* * *

Гүренә кергәнче,
күкләргә ымсыныр,
Адәм баласының
баздан башы чыкмас
хыялы кысыры...

* * *

Өзелеп сибелде
дисбесе ташлары...
Адәм баласының
Бисмилласызының
ташлары ташлады.

* * *

Бербөтен булып та,
ары бүлгәләнсә,
Адәм баласының
нәсел бакчасына
ятлар орлык чәчә.

* * *

Изге хаҗ юлына
җиде кат чыгып та,
Адәм баласының
җаһиллеген йолыр
тәүбәсе чынлыкта.

* * *

Бизмәндә ат көче
тарихка калачак...
Адәм баласының
акылы яктылык
үлчәмен алачак.

* * *

Бизәнүдән өстә
алтынның кирәге...
Адәм баласының
яктылык тизлеген
йөгәнләр зирәге.

* * *

Галәмнәр чигендә

җирдән хәбәрдардыр...
Адәм баласының
«Юк» дигәненнән дә
анда хәбәр бардыр.

* * *

Аулагында калып,
ни-нәрсә кылынмас...
Адәм баласының
зыялы затлысы
хәрәмгә орынмас.

* * *

Алырын алыр да,
бирерме бирәсен?..
Адәм баласының
күзенең агында
күренә ни рәсем?

* * *

Чынында ялган гел
яшеренеп торыр,
Адәм баласын ул,
кинәттән ялтырап,
йөзен чыннан борыр...

* * *

Әйткәне – атканы
үзәгенә тигән.
Адәм баласының
рәнҗегән җанында
җәрәхәте тирән...

* * *

Алмаса артыгын,
бирмәсә киметеп,
Адәм баласының
савапсыз гамәле
язылыр ким итеп...

* * *

Күкләрдә барсы да
исәптә дисәк тә,
Адәм баласының
илтифатсызлыгы
дәвасыз ни хаста?

* * *

Күзне төс иркәли.
Күңелгә якын сүз.

Адәм баласының
ис тоймаганының
хисләре ялкынсыз...

* * *

Ачның күзе намда,
тук күзе хәрәмдә...
Адәм баласының
ачтан тук булганы
тәүбәсез һаман да.

* * *

Милләте соралмас,
өммәте соралыр.
Адәм баласының
өммәте юлында
милләте сан алыр...

* * *

«Мин!» – дигәне – төп сүз,
«Бир!» – дигәне – төпсез.
Адәм баласының
ала белмәгәне
исәптә өметсез...

* * *

Турыдан юл үрле,
ураудан юл такыр.
Адәм баласының
зирәк, тәвәккәле
өр-яңа юл табыр...

* * *

Кушкаенны давыл
аерып ташлады...
Адәм баласының
игезәк якыны
авырый башлады...

* * *

Сүрә, аятендә
Хак юлы сызылган.
Адәм баласының
миһербансызлыгы
имансызлыгыннан...

* * *

Япканы, якканы
талчыбык, курадыр...
Адәм баласының

көн итеп ятканы:
«Шөкер», – дип торадыр...

* * *

Үзенекен саклар,
күршенекен саплар...
Адәм баласының
шушы гамәлләрен
күпчелеге аклар.

* * *

Каплап алган болыт –
бер тамчы таммады...
Адәм баласының,
утырауда калып,
корыга тарганы...

* * *

Үзен кызганудан
кара көйде, янды...
Адәм баласының
шәфкатьсезлегенә
нәфрәте уянды...

* * *

Күренеп тормаса
ышандырсын ничек?
Адәм баласының
хәтеренә керер,
үз башыннан кичеп...

* * *

Үчен чигендерер,
сәбәбенә кереп.
Адәм баласының
ыру-йолаларын
аяусыз җимереп.

* * *

Чүл, саз, котып – җирнең
җиткесез җирләре.
Адәм баласының
шунда яшерелгән
мәңгелек серләре...

* * *

Болыт күкне түгел,
җирне каплап алды...
Адәм баласына
күк күзе тиюдән

шулай саклап калды.

* * *

Көн туса – яңалык:
су баскан, янганнар...
Адәм баласының
ярык тагарагын
ямарга алганнар.

* * *

Теркәлгән тарихы
тора гел орыштан.
Адәм баласының
бизенәсе юктыр
бер-берсен кырыштан...

* * *

Тыелганы татлы
булып тоеладыр.
Адәм баласының
җаны тыелганнар
белән кыеладыр.

* * *

Җиң эче яшерер,
итәге качырыр...
Адәм баласының
кырык елдан соң ук
кырыны ачылыр.

* * *

Хәтере-үткәне
меңьеллык арада...
Адәм баласына
билгесез килере –
мәҗбүри чара да.

* * *

Болытларны куа,
томанны тарата.
Адәм баласының
юк бер мактау сүзе
шул җилгә карата.

* * *

Сүз тәмен тоялмас
сүгенгән авызы...
Адәм баласының
зәһәрен тыялмас
азынган явызы.

* * *

Үр менде тезләрен,
терсәген канатып...
Адәм баласының
күктә игезәге
торды гел җан атып.

* * *

Ганимат малына
кулы бер орынса,
Адәм баласының
ыру-нәселен баса
юлбасар, илбасар.

* * *

Юләр йогынтысы
юлыгасын белсә,
Адәм баласының
keләсен күтәреп
кермәс иде кемсә...

* * *

Күк исе – яфракта,
җир исе – тамырда.
Адәм баласының
җисеме асылы –
нәселе канында.

* * *

Тәүбә итәрендә
бер аять, сүрәсе.
Адәм баласының
җәенке битендә
шайтани сурәте.

* * *

Авызы – ялгызы,
колак, күзе – пардан...
Адәм баласының
тыңлавы, күрүе
мөһим такылдаудан...

* * *

Караңгы чоңгылда
галәмнең аръягы.
Адәм баласының
шунда китәр нурга
әверелеп җаны...

* * *

Чиксез мәңгелекнең
яратылышында
Адәм баласының
фарыз өлеше бар
үз бегланышында.

* * *

Ачу, үч-нәфрәтен
чигендерсә элек,
Адәм баласының
берсеннән берсенә
күчәр сихәт-хөрлек...

* * *

Иксез-чиксез дала –
әрлән, кылган иле...
Адәм баласының,
бар җиһанны яулап,
илсез калган җире...

* * *

Чишмәсен качырмас,
сүндермәс учагын...
Адәм баласының
ут белән су йотып
яшәргә дучары...

* * *

Тарихы – үткәне,
меңьеллык юл узган...
Адәм баласының
китереп җиткергән
чабатасы тузган.

* * *

Түрәне түр көтә,
ярлыны – бусага...
Адәм баласының
күрәсе өркетә,
дәвамы булса да.

* * *

Бардан юк булганы,
юктан бар булганы.
Адәм баласының
шуңар берөзлексез
юлыгып торганы...

* * *

Чылбырга – чыгыры,

Колгага – сиртмәсе...
Адәм баласына,
бер тамчы су эзләп,
галәмгә китәсе...

* * *

Бер карыш гомердә
күпме дау чыгасы?!
Адәм баласының,
берсен берсе кагып,
күпме талчыгасы?

* * *

Өстән караганда,
күпкә кечерәя...
Адәм баласына
төп-төгәл бирелер
шул хәлендә бәя.

* * *

Ара ераклыгы
аклану өченгә.
Адәм баласының
барып җитәрлеге
нияте көчендә...

* * *

Биш юлым – биш гөлем,
Сугарып үстердем:
«Адәм балаларым»
Ташлап китмәс, шөкер,
барысын үз күрдем...

Литературно-художественное издание

**Мирза** Мухаммат
(**Ибрагимов** Илфак Мирзаевич)

**Мои пять строчек – мои цветочки**

Казань. Татарское книжное издательство. 2013
На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Мирза** Мөхәммәт
(**Ибраһимов** Илфак Мирза улы)

**Биш юлым – биш гөлем**

Мөхәррире *Л. Ә. Гыйззәтуллина*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *М. Д. Вазиева*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Н. П. Клипова*
Корректоры *Г. Г. Мөхәммәтҗанова*

Оригинал-макет-тан басар-га кул куелды 31.01.2013. Форматы 70×100 $^{1/32}$.
Шарт-лы бас-ма табагы 8,45. Ти-ражы 2000 д. За-каз

«Та-тарстан китап нәш-рияты» ДУП. 420111. Ка-зан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс:(843) 519-45-22.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: info@tatkniga.ru**

**Безнең китапларны түбәндәге адреслар буенча сатып алырга мөмкин:**
Казан, Декабристлар урамы, 2.
Татарстан китап нәшриятының маркетинг бүлеге. Тел.: (843) 519-45-35.
Казан, Бауман урамы, 29/11.
Татарстан китап нәшриятының фирма кибете. Тел.: (843) 292-03-18.

«Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиг-рафия-нәш-рият комплек-сы.
420066. Ка-зан, Де-каб-ристлар урамы, 2.